КИРӘК КЕШЕЛӘР

Мәктәпкә эшкә студентларны чакырмакчылар

> 5

ТАБЫГЫЗ... ХАТЫН

Ялгызлар өчен дәүләт хезмәте кирәкме?

> 15

НӘҖИП НӘККАШ:

«Татар эзе җуела бара»

> 18–19

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 103 (29070) | Җомга | 21 июль | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

fotokonkurs.ru

ТҮРДӘН УЗЫГЫЗ!

ТАТАРСТАНДА КАЙДА ҺӘМ НИЧЕК ЯЛ ИТЕП БУЛА?

Быел Татарстанда кимендә 4 миллион турист көтәләр. Бу санга гаҗәпләнерлек тә түгел шикелле. Республика кунаклар саны буенча былтыр ук әлеге чиккә якынлашты. Җәйнең кыл уртасында Казан Кремле тирәсендә алма төшәрлек тә урын юк әнә. Чит илгә чыгу мәшәкатьле, өстәвенә юллама бәяләре югары сикерде, ә халыкның сәяхәт итү теләге сүрелми. Бай тарихлы һәм кунакчыл Татарстан туристларны нәрсә белән шаккатырырга сәләтле? «ВТ» хәбәрчесе республикадагы ял итү урыннарын барлады.

> 6–7

Ишетми калмагыз

Депутатлар повестка буенча хәрби комиссариатка килмәүчеләргә штраф күләмен арттыруны тәкъдим итә. Дәүләт Думасының Шәһәр төзелеше һәм законнар чыгару комитеты хәрби хезмәткә чакыру турында законга төзәтмәләрне икенче укылышта кабул итүне хуплады. Үзгәрешләр нигезендә, чакыру кәгазе алып та, хәрби комиссариатка нигезле сәбәпсез бармаучылар 50 мең сумга кадәр штрафка тартылачак. Хәзерге вакытта аның иң зур күләме 3 мең сум тәшкил итә.
Гаилә хәле, яшәү, эшләү урыны турында һәм башка шундый мәгълүматларны хәрби комиссариатка хәбәр итмәгән өчен – 20 мең сумга кадәр, медицина тикшерүе узудан баш тарткан өчен 25 мең сумга кадәр штраф түләргә туры киләчәк. Моннан тыш, төзәтмәләр хәрби учетка куелырга тиешле кешеләр исемлеген военкоматка билгеләнгән вакытта тапшырмаган өчен җаваплылыкны көчәйтүне күздә тота. Моның өчен вазыйфаи затларны – 40тан 50 мең сумга кадәр, юридик затларны 350дән 400 мең сумга кадәр штрафка тартачаклар.

Татарстанда соңгы биш ел эчендә (2018 елдан башлап) Иделгә агызыла торган пычрак су күләме 27,4 процентка кимегән. Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы белгече Елена Закирова әйтүенчә, «Экология» илкүләм проектының «Иделне савыктыру» федераль проекты кысасында тиешле чаралар күрү нәтиҗәсе бу. Аерым алганда, Яшел Үзән районының Карамалы Тау, Васильево бистәләрендә чистарту корылмалары төзелгән, Казанда «Водоканал» корылмалары реконструкцияләнгән.
2014 елдан 2022 елга кадәр судан барлыгы 336 проба алынган. Белгечләр Иделне бигрәк тә марганец һәм тимер матдәсе пычратуын ачыклаганнар. Шулай ук бакыр, нитрит, цинк кебек матдәләрнең дә рөхсәт ителгәннән күбрәк булуын билгеләгәннәр. 2024 елга кадәр «Иделне савыктыру» проектын гамәлгә ашыру өчен 22,3 миллиард сум (шул исәптән 15,5 миллиарды – федераль бюджеттан) таләп ителә.

Быел алты ай эчендә Россиянең 28 төбәгендә кош гриппы очраклары теркәлгән. Чирнең 62 чыганагы ачыкланган, шул исәптән соңгы ике айда – 51 чыганак. Шуның 46сы күгәрчен, чыпчык, карга кебек кешеләр янында яшәүче кошларда һәм акчарлакларда табылган. Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе җитәкчесе урынбасары Габделхак Мотыйгуллин әйтүенчә, илдә кош гриппы очракларының артуы сәбәпле, «Акчарлак» айлыгы игълан ителгән. Ул 10 июльдән 9 августка кадәр үткәрелә. Максаты – хәтәр авыруга юл куймау. Кошчылык хуҗалыклары җитәкчеләренә кош-кортны ябык урыннарда тоту, шулай ук башка таләпләрне үтәү тәкъдим ителгән. Айлык барышында ветеринария белгечләре барлык хуҗалыкларда кош-кортларның баш санын ачыклаячак, өйдән-өйгә йөреп, чирнең нинди куркыныч белән янавын аңлатачак. Моннан тыш үлгән кошларны эзләү чаралары көчәйтелгән, акчарлакларның күпләп җыелу урыннарына – су буйлары, шул тирәдәге урыннар, чүплекләргә рейдлар оештырылган.

Районнарда ни хәлләр?

Чүпрәле

Яңа Чәке авылында Гөлсәйран белән Хәмит Шәрәфетдиновлар нигезендә яңа мәчет ачылды. Авыл агайлары сүзләренчә, авылда мәчет элек тә булган. Әмма ул 1930 нчы елларда сүтелгән. Шуннан соң авыл халкы намазларын өйдә генә, җомга һәм бәйрәм намазларын билгеле бер нигездә укыган. Бүген Яңа Чәке авылында 74 кеше яши. Ә авылда мәчет булдыру идеясен Илдар Шәрәфетдинов тәкъдим иткән. Мәчетне исә нигезнең хуҗабикәсе Гөлсәйран исеме белән атыйлар. Ачылыш чарасына район үзәгеннән башкарма комитет җитәкчесе Рөстәм Мөхәммәтҗанов, мөхтәсиб Данир хәзрәт Шәрәфетдинов, тирә-як авылларның мәчетләре имамнары, авыл җирлеге башлыклары да килде. Бу көнне Яңа Чәке авылында мәчетнең имамы да сайланды. Бу вазыйфаны авылдашлары Илдар Шәрәфетдиновка йөкләде.
(«Туган як»)

Питрәч

30 июльдә Питрәч наратлыгында җиденче тапкыр Бөтенроссия «Скорлупино» фестивале узачак. Быел фестиваль Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елына багышлана, шуңа күрә чарада район территориясендә яшәүче халыкларның милли үзенчәлекләренә басым ясалачак. Фестиваль кунакларын Россия төбәкләреннән килгән осталар һәм һөнәрчеләр ярминкәсе каршы алачак. Берничә оста традицион милли һөнәрләр һәм бизәнү әйберләре ясау буенча мастер-класслар әзерли. Питрәч районы кошчылык белән дан тота, шуңа күрә «Ско-ко – парк» мәйданчыгы күп кенә төр кошларны тәкъдим итәчәк. Фестиваль кунаклары төрле халыкларның иң популяр ризыклары белән сыйланып, яңа ризыклар әзерләү серләрен белә алачак.
(«Алга»)

Актаныш

Актаныштa велосәяхәтче Валерий Сморчков кунак булды. Аны Актанышка кергән җирдә чәкчәк белән танылган һәм һәвәскәр велосипедчылар каршы алды. Валерий Казан – Актаныш арасын дүрт көндә үткән. Аның сәяхәте Казахстан ягына дәвам итә. «Миңа велосипедта йөрү бик ошый! Җәяү кызыклырак булыр иде дә, ләкин вакыт күп түгел. Тизрәк Казахстанга барып җитәсем килә», – ди велосипедчы үзе.
(«Актаныш»)

Чирмешән

«Автоханым – 2023» район бәйгесе җиңүчесе Алинә Дмитриева Казанда республикакүләм ярышларда да үз осталыгын күрсәтәчәк. Райондагы бәйгедә ул бишенче тапкыр катнашса, дүртесендә беренче дәрәҗә диплом белән бүләкләнгән. Сүз уңаеннан, Алинә хәзер декрет ялында. «Автоханым» бәйгесе район үзәгендә ел саен үткәрелә. Быел сигез якташыбыз үзләрен сынап карады», – диде ЮХИДИнең район бүлекчәсе җитәкчесе Рәмис Шәкүров. Икенче урын яулаган Сәвия Сәгыйрованың машина йөртү стажы нибары өч ай, шуңа карамастан, ул да барлык сынауларны уңышлы узды.
(«Безнең Чирмешән»)

tatarstan.ru

Татарстан Премьер-министры Алексей Песошин Казан Кремлендә дәүләт бүләкләрен тапшырды. Биредә сәнәгать, төзелеш, транспорт, медицина, мәдәният, массакүләм мәгълүмат чаралары һәм башка өлкәләрдә уңышка ирешкән 50 кеше – 31 ир-ат һәм 19 хатын-кызны хөрмәтләделәр. Аларның 16сы – Россия Федерациясе, 34е Татарстан Республикасының дәүләт бүләкләренә ия булды. «Намуслы эшегез өчен рәхмәт. Һәркемнең үз эшчәнлеге өлкәсе, үз юлы бар, әмма барыгызны да үз эшенә тугрылык берләштерә, – диде Алексей Песошин тантанада. – Татарстан – күпкырлы традицияләр, кунакчыллык, халыклар бердәмлегенең кабатланмас мисалы. Республика халкының көндәлек хезмәте нәтиҗәсендә проектлар уңышлы тормышка ашырыла һәм социаль-икътисадый үсешкә ирешәбез. Нәкъ менә сезнең талант, тырышлык һәм ныклык республикабызны көчле һәм алдынгы итә».

ХЕЗМӘТ НӘТИҖӘЛЕ БУЛСЫН

Казанда алдынгы компанияләр идарәчеләре һәм белгечләр хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру хакында фикер алышты. 20–21 июльдә башкалада «Җитештерүчәнлек 360» V федераль форумы узa. Анда Россиянең 64 төбәгеннән 500дән артык эре һәм урта компанияләр җитәкчеләре катнаша.

«Хезмәт җитештерүчәнлеге» илкүләм проекты республикада инде бишенче ел гамәлгә ашырыла. Ә быел Татарстан бу эштә лидер төбәк дип танылды. Бездә илкүләм проектта 200дән артык предприятие катнаша.

«Татарстан – сакчыл технологияләр куллану буенча лидер төбәкләрнең берсе». Федераль компетенцияләр үзәге (ФЦК) генераль директоры Николай Соломон сүзләре бу.

– Илкүләм проектта катнашучыларның гомуми табышы 11 трлн сумнан артып китте. Бу – безнең икътисадның шактый өлеше. Сакчыл җитештерү елдан-ел икътисадның киңрәк өлешен колачлый. Бүген безнең сафта 5 меңнән артык компания бар. 2,3 мең компания Россиянең тулай эчке продуктына 400 млрд сумга якын өлеш кертте. Әлеге компанияләр үзләре 61 миллиард сумнан артык табыш алды. Хәзерге шартларда бу бик мөһим һәм үз вакытында дип саныйм, – диде Николай Соломон.

Ел саен форумда актуаль трендлар карала. Быелгысында булган ресурсларны кулланып, нәтиҗәлелекне арттыру, үзгәреп торган шартларны исәпкә алып, предприятие үсешенә юнәлтү турында фикерләштеләр. Машина төзелешенең киләчәге, икътисадның төрле тармаклары өчен цифрлы чишелешләр, кадрлар әзерләү кебек темаларга панель сессияләр узды.

Россия икътисадый үсеш министры урынбасары Морат Керефов республикада илкүләм проектны тормышка ашырудан канәгать калуын әйтте.

– Төбәктә уңай динамика күзәтелә. Берничә предприятиедә булдык, заманча производстволары бар, аларда үсеш темплары, предприятие табышы, хезмәт өчен түләү фондлары күренә. Республиканың җитди бурычларны гамәлгә ашыра торган профессиональ командасы бар. Төбәк компетенцияләр үзәге инде биш ел рәттән илнең иң көчле үзәкләре рәтенә керә. Бу үсеш республика икътисады өчен генә түгел, ә тулаем ил икътисады өчен мөһим, – диде министр урынбасары.

2024 елга илкүләм проект җитештерүчәнлек үсеше темпларын елына 5 проценттан да ким түгел, ә хезмәт җитештерүчәнлеге үсешен 20 проценттан артык тәэмин итәчәк, дип планлаштырыла.

Форумның пленар утырышында Татарстан Премьер-министры Алексей Песошин катнашты. Аның сүзләренә караганда, республика һәрвакыт барлык тармакларда югары күрсәткечләргә ирешүгә омтыла. «Хезмәт җитештерүчәнлеге» илкүләм проектын тормышка ашыруда алдынгы булуның сере әнә шуннан гыйбарәт. Хәзерге вакытта илкүләм проектта Татарстаннан 226 компания катнаша. «Күптән һәм җентекле эш алып алып бару нәтиҗәсендә рейтингта беренче урынга күтәрелдек. Илкүләм проект барлыкка килгәнче үк бездәге предприятиеләрнең нәтиҗәлелеген арттыру белән шөгыльләндек. Әле 2012 елда ук республикада «Сакчыл җитештерү» программасын расладык. Ул әле дә гамәлдә, – диде Алексей Песошин. – Шуңа күрә безнең күпмедер күләмдә өстенлек һәм тәҗрибә бар иде. Бу юнәлештә эш дәвам итәчәк».

Ләйсән САФИНА

Татарстанда – капиталь төзекләндерү

Быел Татарстанда социаль-мәдәни өлкәгә караган 606 объектта капиталь төзекләндерү эшләре башкарырга ниятлиләр. 22 республика, 2 дәүләт һәм 4 федераль проект буенча бу эшкә 15,7 млрд сум акча тотылачак. Бу саннарны «Татар-информ»да узган очрашуда төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрының беренче урынбасары Алексей Фролов җиткерде.



«Татар-информ»

Мәгариф тармагында **7** программа буенча **234** объект төзекләндерелә
Шул исәптән:
- **5** балалар бакчасы
- **42** мәктәп
- **143** мәктәп ашханәсе

Сәламәтлек саклау тармагында **149** объект төзекләндерелә
Шул исәптән:
- **118** беренче звено учреждениесе
- **31** стационар учреждение

Мәдәният тармагында **4** программа буенча **44** объект төзекләндерелә
Шул исәптән:
- **34** авыл мәдәният йорты
- **10** белем бирү учреждениесе

Яшьләр сәясәте тармагында **5** программа буенча **28** объект төзекләндерелә
Шул исәптән:
- **6** балалар сәламәтләндерү лагере
- **4** үсмерләр клубы
- **8** яшьләр үзәге

Башка юнәлешләр буенча:
- **13** хәрби комиссариат бинасы
- **12** авыл җирлеге башкарма комитет бинасы

БОЛГАРДА БЕР КӨН,

ЯКИ «ЯҢАРЫШ: ДАСТАННЫҢ ЗАМАНЧА УКЫЛЫШЫ» ФЕСТИВАЛЕ ӨМЕТЛӘРНЕ АКЛАРМЫ?


tatarstan.ru

Дәвер вакыйгасы. Маңкортка әйләнмәс өчен үткәрелә торган зур чара. Болгарда узучы «Яңарыш...» фестивален шулай дип атаганнар иде. Тамырларыбызның кайда булуын искә төшерергә тиешле әлеге вакыйганы күреп калыр өчен, Болгарга юл тоттык. Изге җирдә ниләр бар?

Ага базар...

Фестивальнең берничә юнәлештә узуы турында язган идек инде. Шуларның берсе – «Ага Базар» ярминкәсе. Россия төбәкләреннән һәм якын чит илләрдән килгән осталарның эшләнмәләре белән без дә танышып кайттык. Кеше аз булуыннан файдаланып, иң чуар чатырларның берсен әзерләгән Үзбәкстан осталары белән аралаштык.

– Без «Модная Бухара» брендын тәкъдим итәбез. Ярминкәдән тыш, мода күрсәтүдә дә катнашачакбыз. Сату ягыннан карасаң, эшләнмәләрне алучылар бик аз. Ләкин кызыксынучылар җитәрлек, – диде Ирина Шәрипова.

Үзенчәлекле, безнең өчен ят булган эшләнмәләрне Ингушетиядән килгән осталар да тәкъдим итте. Аларның чатыры янынннан тиз генә китә алмадык. Ингуш хатын-кызларының традицион баш киемнәре турында сөйли башлаган әңгәмәдәшебез үз халкының үткәненә «алып кайтты».

– Кызганыч, ингушлар турында бик аз беләләр. Без тарихыбызны эшләнмәләребез аша күрсәтергә тырышабыз. Әйтик, әлеге ярминкәгә киездән ясалган келәмнәр алып килдек. Аларның күпчелеге петроглифлар (ташка ясалган борынгы сурәтләр) белән бизәлгән. Элек-электән аларның яман күчләрдән саклавына ышанганнар, манараларга төшергәннәр. Моннан тыш, күп кенә эшләнмәләрдә кояш сурәтен күрергә мөмкин. Бездә ул – яшәү, тормыш символы. Шуңа да әлеге элемент һәрвакыт хатын-кызларның баш киемнәрендә дә була, – дип сөйләде Айса ханым Сылтиева.

Күрше Башкортстаннан килгән осталарның да хәлләрен белештек. Башкорт балы, шифалы чәйләр белән бергәттән милли киемнәр, эшләнмәләр дә алып килгән алар.

– Бездә 60 ел дәвамында «Агыйдел» башкорт сәнгать һөнәрчелеге» дип аталучы күптармаклы җитештерү үзәге эшли. Фабрикабызда төрле халыкларның милли киемнәрен дә тегәбез, – дип сөйләде Гөлүсә Ризванова. Күпләп җитештерелгәч, бәяләре дә кулайдыр инде, дип кызыксындык. – Бер кеше генә эшләсә, салымнар, хезмәт хакы түләү кебек мәшәкатьләр булмый. Ә фабрикада җитештерелгән эшләнмә бәясенә менә шулар да өстәлә. Шуңа да милли киемнәр шактый кыйммәт. Сездә көндәлек тормышта да милли кием элементларын яратып кияләр, моңа игътибар бирелә. Ни кызганыч, бездә милли кием бәйрәмнәрдә генә искә төшә...

Пәйгамбәр шут була алмый

Осталарга сокланып туйганнан соң, театраль лаборатория белән танышасы иттек. Аны фестиваль кысасындагы мөһим чараларның берсе дип атаганнар иде. Казан һәм ГИТИС студентларына халкыбыз өчен мөһим булган ике әсәрне – Чыңгыз Айтматовның «Мәңгелек буран»ын һәм Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф»ын эскиз итеп күрсәтү бурычы куелды. Эскизлар Россия театр сәнгате институты ректоры, филология фәннәре кандидаты кебек югары дәрәҗәләргә ия булган Григорий әфәнде Заславский җитәкчелегендә әзерләнде. Ләкин милли код салынган әсәрләрне ким дигәндә аңлау өчен югары сәнгать вәкиле булу яисә иң күренекле театр мәктәбендә уку гына җитмидер ул...

Бу шикләрне лабораториядә катнашучы бер төркем яшьләрнең репетициясе раслады. «Кыйссаи Йосыф» әсәреннән эскиз әзерләгән чаклары иде аларның. Күпчелек төркемнәр кебек үк, бу әсәрнең Йосыф – Зөләйха турындагы өзеген алганнар. Эскизны итальяннарның борынгылардан саналучы «комедия дель арте» (башкача – битлекле комедия) жанры кысасында әзерләүләре, дөресен генә әйткәндә, аптырашта калдырды. Сәнгатьтә чикләр юк, дисәләр дә, пәйгамбәрдән комик персонаж, шут ясау, гуманизм башлангычы образы булган Зөләйханы мескен итеп күрсәтү кысага сыймый инде ул. Режиссер ярдәмчесе, ГИТИСның икенче курсын тәмамлаган Ильяс Гирфановтан әсәрне ничә тапкыр укып чыктыгыз, дип кызыксындык. «Көненә әллә ничәшәр тапкыр укыйбыз. Ләкин безнең максат – Йосыф һәм Зөләйханы күрсәтү түгел, аларның мәхәббәт тарихын сөйләү», – диде ул. Әмма ни өчен нәкъ менә комик жанр сайлануын аңлатмады. Бәлки, киләсе фестивальгә үзебезнең дастаннарның «заманча укылыш»ын тәкъдим итәр өчен үзебезнең режиссерларны, үзебезнең студентларны чакырырга кирәктер?

«Яңарыш: дастанның заманча укылышы» фестивале 23 июльдә тәмамланачак. Бу көнне берьюлы берничә зур чара уздырырга ниятлиләр. Шуларның берсе – Татарстанның чигүле картасын тәкъдим итү. Моннан тыш, 23 июльдә ачык һавада һәм тарихи урында янәдән «Кара пулат» операсын күрсәтәчәкләр.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

Сөйләшик әле!

Татарстанның Төбәк белән идарә итү үзәге (ЦУР) белгечләре социаль челтәрләрдә халык белән аралашуда иң ачык район башлыклары исемлеген төзегән. Рейтингны булдыру өчен белгечләр түрәләрнең шәхси сәхифәләрен тикшергән.

2023 елның беренче яртыеллыгы мәгълүматлары буенча, Апас, Менделеевск һәм Яңа Чишмә районнары «иң-иң»нәре булып чыккан. Исемләп әйткәндә, болар – Радмир Беляев, Айрат Җиһаншин, Вячеслав Козлов. Исемлеккә шулай ук Мөслим районы башлыгы Альберт Хуҗин, Чистай районы башлыгы Дмитрий Иванов, Чүпрәле районы җитәкчесе Марат Гафаров, Әлмәт районы башлыгы Тимур Нагуманов, Буа районы башлыгы Ранис Камартдинов, Арча районы башлыгы Илшат Нуриев һәм Чирмешән районы башлыгы Рамил Әйбәтов.

Ел башында «ВТ» хәбәрчесе дә район башлыкларының социаль челтәрдәге активлыкларын тикшергән иде. Тикшерүләребез нәтиҗәсендә интернет челтәрен халыкка якынайта торган күпер итеп салучылар рәтенә без дә **Илшат Нуриев** (Арча), **Тимур Нагуманов** (Әлмәт), **Айрат Җиһаншин** (Апас), **Рамил Нотфуллин** (Балтач), **Ранис Камартдинов** (Буа), **Вячеслав Козлов** (Яңа Чишмә), **Радмир Беляевны** (Менделеевск) керткән идек. Тикшерү өчен «ВТ» район башлыкларының «ВКонтакте» социаль челтәрендәге сәхифәләрен алды, сәхифәдә халык өчен ачык булган мәгълүмат – аудиторияне колачлау, караулар саны (уртача күрсәткеч), язылучылар активлыгына игътибар итте.

ЦУР белгечләре шәхси сәхифәләрнең эчтәлегенә, мәгълүматны җиткерү теленә игътибар иткән. Алар ачыклаганча, социаль челтәрләрдәге халык гозерләренә район башлыклары йә үзләре, йә матбугат хезмәте вәкилләре җавап бирә. Моннан тыш, ЦУР китергән мәгълүматларга ышансаң, башлыкларның 60 проценты эшчәнлегенә бәйле язмалардан тыш, гаилә, шәхси мавыгулары, спорт, йорт хайваннарына бәйле контент белән дә уртаклаша икән. Иң кызыгы: мондый эчтәлектәге яңалыкларны халык аеруча үз итә.

Фикер

Илшат НУРИЕВ, Арча районы башлыгы:
– Әлбәттә, бүген без тормышны социаль челтәрләрдән башка күз алдына да китерә алмыйбыз. Аның уңай яклары күп дип саныйм. Ул безгә аралашу, фикер алышу, яңалыклардан хәбәрдар булу өчен менә дигән мәйдан. Социаль челтәрләрне карап барырга тырышам. Кайбер кешеләр көнүзәк проблемаларны күтәрә. Төрле үтенечләр белән мөрәҗәгать итәләр. Арабызда әйләнә-тирәгә битараф булмаганнар яшәве сөендерә. Вакытында бу проблемаларны хәл итүгә, оператив җавап бирергә, күз уңында тотарга, мәсьәләне уңай якка үзгәртергә тырышабыз.

Марсель ГЫЙЛЬМИЕВ, Татарстанның «Диалог Регионы» коммерцияле булмаган автоном оешмасының бүлек җитәкчесе:
– Халык өчен социаль челтәрләр – сорауларына җавап табу һәм мәгълүмат алу өчен уңайлы мәйданчык. Район җитәкчеләренә исә бу элемтә кору өчен нәтиҗәле ысул. Татарстан районнары башлыклары социаль челтәрләрдә үзләрен күрсәтә башлады.

Әйтеп кенә бактым

Кояш

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

Биектаудагы дачада сырт кыздырып ятыш. Хәер, кызынырга кояшы да юк әле аның. Күңелне ымсындырып, болыт килгәндәй итә – яңгыры юк. Табигатькә әллә ни булды быел, кеше белән бергә көйсезләнә. Кәефне җибәрерлек хәбәр-яңалыклардан качарга тырышып, дачада бикләнеп яткан булам, янәсе, дөнья мәшәкатьләреннән арынып торам. Арынырсың, бар! Күңелне дүрт сутый җирдә бикләп тотып булмый шул.

Әнә болытларны аралый-аралый, кояш чыгып маташа. Саумы, кояш! Ярый әле күк йөзендә син бар. Җирдәге бар матурлыкны, шул исәптән чибәр кызларны да сиңа тиңлим. Күктә – син, җирдә алар дөньяны җылыта.

Балачактагы бер хатирә искә төште. Кояш тотылган көн иде ул. Безгә укытучыларыбыз, әлеге гаҗәп хәлне күзәтү өчен, я киноплёнканың кара өлешен табып, я корымга буялган пыяла әзерләп куярга кушты. Ул заманда укытучы сүзеннән чыгу юк иде, үзебезгә генә түгел, хәтта кызларга да кирәк-ярак хәстәрләп куйдык. Менә җитте кояш тотылыр вакыт. Бөтен мәктәп – урамда, кайбер җүләрләр, кояшка якынрак булыйк, яхшырак күренер дипме, койма, агач башларына үрмәләде. Җүләр дими кем дисең инде аларны, ике-өч метр югары үрмәләп, кояшка якынаерга ул сиңа мәктәп күршесендәге Хәсби абзый йорты түгел. География укытучысы Мансур абый безгә җирдән кояшка хәтле йөз илле миллион чакрым чамасы юл дип аңлата иде. Аннан соң: «Төгәл кем үлчәгән инде аны», – дип тә куя иде.

Менә берзаман кояш каплана башлады. Бу аның тулысынча тотылуы иде, көз ае, әйлә вакыты кебек истә калган. Дөнья кыска гына вакытка караңгылыкка чумды, көн кинәт суытып җибәрде. Күңелне курку алды. Житмәсә, кемдер: «Дөнья бетә!» – дип кычкырып җибәрде. Укытучылар безне тынычландырырга ашыкты: «Борчылмагыз, дөнья бетми, кояш безгә карарга ярдәм кына тора. Әнә бер чите инде күренә дә башлады», – диештеләр...

Бу хәлдән соң күп еллар узды, әмма курку хисе күңелдән һаман да чыгып бетә алмый. Бу хисне яшәеш, тормыш үзе яңартып тора. Кешелек кояшка гомер-гомергә яшәү, тормыш чыганагы итеп караган, кояш турында шигырьләр, җырлар иҗат иткән. Туганнарына, дусларына кояш гомере теләп, котлаулар юлламаган кеше бар микән? Ә бүген кемнәрдер өчен кояш мәңгегә сүнәргә мөмкин һәм моңа еш кына «кеше» дигән җан иясе үзе гаепле. Мин инде табигать бәла-казаларын әйтеп тә тормыйм. Бүген дөньяда «җан бүлешү», кемнең яшәргә хакы бар, кемнең юк икәнен ачыклау бара. Дин буенча бу мәсьәлә хәл ителгән: кешегә гомерне Алла бирә, Алла кире дә ала. Тормыш башлану һәм бетү Илаһи затка бәйле икән, бу бөтен тереклеккә дә кагылами, әллә кешегә генәме? Без аңламаган һәм аңлый алмый торган нәрсәләр күп әле ул. Әмма шуны әйтәсе килә: кеше гомере, аның яшәеше, бу дөньяда үзен ничек тотарга тиешлеге һәр илнең үз законнарында, халыкара документларда язылган. Кеше, уйлый белә торган җан иясе буларак, башкалардан аерылып тора, димәк, үзе үк кабул иткән уртак кагыйдәләр буенча яшәргә тиеш. Әмма бүген үзен генә хаклы дип санаучылар ишәйде. Андыйлар законнарны үтәми, я үз файдасына үзгәртә. Заманында фашизмга каршы сугышкан кайбер илләрнең тәртәләрен кире боруы, Япониянең үзенә атом бомбасы ташлаган Американы аерылмас дус итүе башка сыймый. Бүген телдән төшмәгән кассеталы бомбаларны немецлар уйлап тапкан һәм аны үзләре үк әле 1939 елда ук полякларга каршы кулланганнар. Бүген исә әлеге ике ил – аерылмас дуслар.

2008 елда кассеталы сугыш коралларын кулланмау турында Халыкара конвенция эшли башлады. Аны йөзләп дәүләт хуплаган иде. Әмма Америка белән Украина, ни сәбәп, баш тарттылар. «Ни сәбәп» икәне аңлашыла инде. Димәк, Европада демократия урнаштырып йөрүче Америка Россиягә каршы сугышта Украинаны кулланачагын алдан ниятләп куйган, һәр ике ил бүгенге язгышка алдан әзерләнгән дигән сүз. Кассеталы бомбалар халыкны күпләп юк итү өчен кулланыла. Әгәр Америка аларны «демократия хакына» Украинага бирә икән, эшнең кая таба барганын чамаларга мөмкин. Әлеге бомбалар солдатларны һәм гади халыкны аерып тормый, галәмәт зур мәйданнарда бар тереклекне юк итә. Ә Украина кассеталы бомбаларны һәм снарядларны безгә каршы кулланса, без нәкъ шуның белән җавап та бирәчәкбез – җитәкчеләр шулай ди. Инде эш шулай ук күпләп юк итү коралы саналган атом бомбасын куллануга гына барып җитмәсен иде. Ул очракта йөз меңләгән түгел, миллионлаган кеше өчен кояш мәңгегә сүнәчәк. Үзем куркам, үзем йолкам дигәндәй, бу юлларны язганда, күңел тынычсызлана һәм бала чагым, кояш тотылып, дөньяның караңгылыкка чумуы искә төшә. Һәм: «Барыбызга да бер кояш, нигә шуның җылы нурларында коенып, матур итеп гомер итмәскә икән...» – дип уйлап куям. Әй, кешеләр...

ЧЫПЧЫК БЕЛӘН АКЫЛ ДА ЮГАЛА

Экстремаль эсселек нәтиҗәсендә Төркиядә бер көн эчендә 19 урман янгыны башланды. Төрекләрнең «Duvar» яңалыклар сайты соңгы көннәрдә шундый хәбәр урнаштырды. Илнең авыл һәм урман хуҗалыгы министры Ибраһим Юмаклы 16 июльдә Хатай, Мәрсин, Чанаккала провинцияләрендә бер көн эчендә башланып киткән янгыннарның төп сәбәбе дип көчле эсселекне атый.

Америка телевидениесе дә шуңа охшаш хәбәрләр тапшыра. Канададагы урман янгыннарының төтене Американы каплап алды, ди. Браун университетының Әйләнә-тирә һәм җәмгыять институты директоры: «Экстремаль күренешләр глобаль җылынуның һәр адымы саен артачак», – дигән фикер әйтә. Сүз янгыннар хакында гына бармый, әлбәттә. Гадәттән тыш көчле давыллы яңгырлар нәтиҗәсендә су басулар да еш була. Статистикага карамыйча да, бу дөньяда яшәп сакал агарткан кеше буларак шуны әйтә алам: аномаль табигать күренешләре моннан ярты гасыр элеккегә караганда күпкә ешрак очрый. 50 ел – климат үзгәрешләре өчен бик кыска ара, объектив нәтиҗә ясау өчен гасырлар югарылыгыннан торып фикер йөртү сорала. Шуңа карамастан, инде хәзерге яшьләр дә кайбер нәтиҗәләр ясый ала, чөнки үзгәрешләр кызулана. Әхлаксызлык һәм бозыклык сазлыгында батып баручы кешелек җәмгыяте авыр сынаулы һәм сикәлтәле чорга кереп бара.

Моннан ике ай ярым тирәсе элек Россиянең Куркынычсызлык Советы секретаре Николай Патрушев «Известия» газетасына интервью биргән иде. Анда ул Россиянең көнбатышында барган конфликтны Американың Россияне яулап алырга омтылышы нәтиҗәсе буларак күрсәтә. «Америкага Россия нигә кирәк?» дигән сорауга каршы (соңгы утыз елда болай да бит инде без яшәгән киңлекләрнең бар байлыгы көнбатышлыларга хезмәт итте) ил сәясәтен билгеләүче төп шәхесләрнең берсе, озакламый АКШта Йеллоустоун супервулканы атачак һәм Төньяк Америкада бар тереклек һәлак булачак, дигән фикер белдерде. Бу идеяне «заговор теориясе» тарафдарлары моннан 20–25 еллар элек үк тараткан иде инде. Ә Көнчыгыш Европа һәм Себер яшәү өчен иң уңайлы төбәкләр булып калачак. Нәкъ менә шуның өчен дә Көнбатышның Хартлендны (Евразиянең төньяк-көнчыгыш өлешен) яулап алырга тырышуы турындагы фикерне кызыл җеп итеп үткәрде ул.

Юк, без зур дәүләт чиновнигының сүзләрен шик астына алырга җыенмыйбыз, әлбәттә, әмма Патрушев сөйләгәннәр газета хәбәрчесенә моннан күп еллар элек мәгълүм иде инде. Андый гипотеза яши. Чынлап та, АКШтагы Йеллоустоун милли паркында шул исемдәге супервулкан бар һәм аның кальдерасында берничә дистә ел дәвамында зур үзгәрешләр күзәтелә. Алар вулканның көннәрдән бер көнне уяначагын дәлилли. Ләкин ул дәһшәтле вакыйганың кайчан буласын гына әйтү кыен. Бәлки иртәгә үк булыр, бәлки бернечә йөз елдан соң. Моннан 2 миллион ел элек Йеллоустоун вулканы 50 километр биеклеккә кадәр таш һәм көл аткан, диләр. Шундый куәттәге яңа бер атыш башланса, планетакүләм зур катастрофа булачак һәм шик юк: кешеләрдә сугыш һәм акча-мал кайгысы калмаячак. Төньяк Америка гына һәлак булырмы, әллә фаҗига планетакүләм масштабны алырмы, белеп булмый. Шуңа америка映нарның Себергә күчеп яши башларга теләүләре – «заговор теориясе»нең бер тармагы гына ул. Без әйтсәк, «фейк» дип кабул ителер иде, Патрушев әйткәч, рәсми югарылыкка күтәрелә һәм пропаганданың бер сөңгесенә әверелә.

Көнчыгыш Европа – Себер (Патрушевча әйтсәк, Хартленд) без яшәгән төбәкне дә үз эченә ала бит инде, шуңа күрә безгә америкаалар агрессиясенә каршы берләшергә генә кала. Әмма Йеллоустоун вулканы әллә ата, әллә юк, ә менә климатның глобаль үзгәрешләре бүген үк бара инде һәм алар фонында кайбер галимнәр безгә бер дә күңелле киләчәк юрамый. Урман янгыннары кочагында калган Канаданың кайбер төбәкләрендә июнь температурасы климатик нормадан 14 градуска югары булган. Галимнәр быелгы июльнең һава температурасының иң югары рекордын бирүен раслый. Мәскәү дәүләт университетының (МГУ) биологик эволюция кафедрасы профессоры Андрей Журавлев Россиянең, аеруча Себернең киләчәген бер дә яхшыга юрамый. Себер мәңгелек боз катламы өстендә утыра. «Җылыну билгеле бер киеренкелек ноктасына җитүгә, – ди профессор, – боз катламы яшен тизлегендә эреп бетәр, йортлар авар, юллар юкка чыгар, тайга тулысынча янгыннар кочагында тәтенгә әйләнер һәм без технологик эраның иң башына алып ташланырбыз». Электр да юк, газ да юк, эчке януны двигательләр дә эшләми, электромобильләр турында хыяллана да алмыйбыз дигәнне аңлата Журавлев фаразлары.

Бер нәрсә белән юана алабыз: болар барысы да – гипотезалар, вәләкин ул гипотезаларның ваграк масштабларда тормышка ашып баруы барыбер күңелне сагайта. Кыскасы, климат җылынса, без яшәгән киңлекләрдә пальмалар һәм ананаслар үсә башлар, дип сөенергә җирлек аз.

Кешелек җәмгыятенең табигатькә тәэсире чиктән ашты. Әйе, без табигать шартлары бик үк уңай килмәгән илларда да шактый ук мул уңыш җыеп алабыз. Ач калган юк, кыскасы. Бу – пестицидлар һәм ашламалар куллану нәтиҗәсе. Әмма бу юлларның авторы соңгы елларда бер нәрсәгә игътибар итә. Моннан утыз еллар тирәсе элек ишегалдын каргалар басып ала иде. Тавыкка куйган азык савыты өстеннән аларны куып бетереп тә булмый иде. Хәзер күзгә кырып салырлык бер карга юк. Чыпчыклар белән шул ук хәл. Чыркылдап теңкәгә тия торган бу кошларны табу өчен, авыл урамнарын иңләргә кирәк. Әле ярый яз саен сыерчыклар кайта. Алар ничектер пестицидлар афәтеннән имин кала. Бәлки, кырларны агулый башлауга, яшәргә урманга күчүләре саклый торгандыр. Кошларның сирәгәюе киләчәктә пестицидларсыз иген игеп булмаячагын аңлата. Чыпчыкларны үтереп бетереп, иген уңышыннан колак каккан Мао чоры Кытаеның чит илләрдән чыпчык сатып алырга мәҗбүр булуын искә төшерик.

Кошларның һәлакәте – бәланең яртысы гына бит әле ул. Пестицидлар – чып-чын агу һәм кеше организмына да тәэсир итми калмый. АКШ Конгрессының элекке вәкиле Тулси Габбард Твиттерда авыл хуҗалыгы культураларына сибелгән химикатларның җенескә кагылышлы үзгәрешләр китереп чыгаруы хакында шау-шу кубара, мәсәләнн. Аның фикеренчә, пестицидлар ирләрдә шундый үзгәрешләр китереп чыгара: алар үзләрен хатын-кыз итеп тоя башлый. Атразин дигән пестицидның (ул Россиядә дә кулланыла) гендер проблемалары китереп чыгаруы хакында, имештер, дәлилләр җитәрлек, диләр. Ирләрдә ирлек сыйфатлары бетү, аларның хатын-кыз итәге киергә тырышуы – эпидемия масштабына әверелеп бара торган проблема. Россиядә тик торганнан гына җенесне алыштыру буенча операцияләрне тыю турында канун әвәләп мәшәкатьләнмиләр бит инде. Димәк, проблема бар, аның статистикасы гына безгә мәгълүм түгел. Көнбатышның идарәче катлавы пестицидларның химик кастрация китереп чыгаруын рәсми рәвештә кире кагалар кагын, аны «заговор теориясе»нә кертәләр. Ә банкирларның соңгы көннәрдә ЛГБТга каршы чыккан шәхесләрнең банк хисапларын бикләүләре нәрсә? Ул каян килә? Көнбатыш илләрендә генә түгел, элекке совет республикаларында да күзәтелә ул хәл. Грузиядә, мәсәлән, соңгы көннәрдә генә банкирлар «зәңгәр»ләрне һәм «ал-су»ларны сөймәүләрен белдергән кешеләрне акчасыз калдырды. Кабахәтлекне дөньякүләм алга этәрүче көч бар ул, бар. Шулай булмаса, бар кеше берьюлы акылдан яза алмый бит инде.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

УКЫТЧЫ, УКЫТУЧЫ!

ПЕДАГОГЛАРГА КЫТЛЫКНЫ НИЧЕК ХӘЛ ИТӘРГӘ ҖЫЕНАЛАР?

Татарстанда яңа уку елында 1500 укытучы һәм тәрбияче кирәк. Мәктәпләрдә бигрәк тә башлангыч сыйныф, математика, физика, рус теле һәм әдәбияты укытучылары җитми. Казан һәм Чаллыда, Лаеш районында тәрбиячеләргә кытлык бар. Дәүләт Думасында булачак укытучыларны укуларын тәмамлаганчы ук мәктәпкә җибәрергә тәкъдим итәләр. Тагын нишләп була? «ВТ» хәбәрчесе республикадагы вазгыятьне белеште.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Кире кайтмыйлар

Чирмешән районының Түбән Кәминкә мәктәбендә яңа уку елында 19 бала белем алачак. 1 нче сыйныфка 3 укучы бара. Мәктәпне исә бишәү тәмамлаган.

– Бездә математика, физика укытучыларына кытлык бар иде. Аптырагач, узган ел, сөйләшеп, Әлмәттә укыткан үзебезнең район егетен кайтарттык. Утыз чакрым ераклыктагы туган авылыннан килеп, математика, физика, информатика фәннәрен укыта. Башка авыл укытучылары да эшли. Быелга укытучылар җитә, – ди директор урынбасары, инглиз теле укытучысы Гөлназ Массарова.

Әмма моның белән генә тынычланып булмый. Директор урынбасарын вузларга укырга җибәрелгән «целевик»ларның кире кайтмавы борчый. Яшь белгечләр күбрәк Әлмәт, Түбән Камадагы мәктәпләрне сайлый икән. Ни өчен дигәндә, гамәлдәге тәртип буенча, аларны үз районнарына кайтырга мәҗбүр итә алмыйлар. Яшь белгечләргә Татарстанның теләсә кайсы мәктәбендә укытырга рөхсәт ителә.

– Аларны кайсы район җибәрә, шунда эшкә кайтсыннар иде. Элеккеге кебек юллама системасын кайтару да кирәк, – ди Гөлназ Массарова. – Монысы – хыял, ә чынбарлык башкачарак. Аңлыйм мин, яшь укытучыларны мәктәптә хисап эшенең күп булуы, әти-әниләр белән эшләү дә куркыта. Хәзерге әти-әниләр бала сүзен генә ишетә. Әниләр бала алдында укытучы дәрәҗәсен төшерергә генә тора. Кызганыч, мондый күренеш авылга да үтеп керде. Элек укытучының нинди абруйга ия булганын хәтерлибез бит. Хәзер андый нәрсә юк инде.

Кукмара районының Ядегәр мәктәбендәге хәлләрне дә белештек. Хәтерләсәгез, моннан өч ел элек шушы мәктәпне тәмамлаган Инсаф Фәйзрахманов БДИда 393 балл җыйган иде. Мәктәп директоры Рамис Нуриев белдергәнчә, аларда хәзерге вакытта бары рус теле һәм әдәбияты укытучысы гына җитми. Яшь укытучылары декрет ялына киткән. Яңасын Мәшгульлек үзәге аша эзлиләр.

– Безнең коллективта эшләүчеләр әлегә әллә ни олы яшьтә түгел. Пенсионерлар юк. Химия укытучысы гына күрше авылдан килеп укыта. Башкалары барысы да – үзебезнеке. Әлегә кадрлар кытлыгы юк. Әмма тагын биш елдан бу проблема бик актуаль булачак. Шуңа күрә үзебезнең укучыларны педагогия уку йортларына укырга җибәрергә кирәк. Мәсьәләне бары тик шулай гына хәл итәргә мөмкин, дип саныйм, – ди Рамис Нуриев.

Өй һәм җир бирәләр

Менделеевск районының мәгариф идарәсе башлыгы Рәис Нәҗипов та районда күп юнәлешләрдә укытучыларга кытлык булуын әйтте. Әйтик, математика, физика, химия, информатика, биология укытучылары, татар телендә укыта һәм тәрбия бирә торган башлангыч сыйныф укытучылары, тәрбиячеләр җитми. Мәгариф идарәсе Арча педагогика көллияте, Чаллы дәүләт педагогика университеты белән татар балаларын укытып, районга кайтару турында сөйләшкән.

– Укытучыларга ярдәм турында уйланабыз. Районда 75 квадрат мәйданлы йортлар төзү, унлап җир кишәрлеге, «подъемный» акчасы бирү буенча программа булдырылган. Менделеевскидагы «Аммоний» заводы химия-технология лицее укытучыларына ай саен 350 мең сум акча түли. Үзебезнең кадрларны укытмыйча булмый. Педагогика вузларына барырга теләгән укучыларны җыеп, ике педагогика-психология сыйныфы ачтык. Без моны Чаллы педагогика көллияте белән бергә оештырабыз, – ди Рәис Нәҗипов.

Ышанырлармы?

Илдә мәгариф түрәләре укытучылар кытлыгын бетерүнең төрле юлларын эзли. Әнә педагогия көллиятләрендәге югары курс студентларын мәктәпләргә, бакчаларга эшкә җибәрмәкчеләр. Әлеге закон проекты Дәүләт Думасының икенче укылышында кабул ителгән.

– Без укыган вакытта эшләргә теләгән студентларга мөмкинлекләрне арттырабыз, – ди Дәүләт Думасының Мәгариф комитеты рәисе Ольга Казакова.

Аңа кадәр Дума Рәисе Вячеслав Володин әлеге карарның мәктәпләрдәге, бигрәк тә авыл җирлегендә кадрлар кытлыгын хәл итәргә булышачагын белдергән иде. Диплом алганда инде мәктәпкә тәҗрибәле белгеч булып барачаклар. Әнә шуңа өметләнәләр.

Бу алым мәктәпләр өчен һич югы саламга ябышу булса, әти-әниләр моңа бөтенләй каршы.

– Безнең балалар белән тәҗрибә уздырмасыннар иде. Яшь белгеч үзе дә әле яңа гына мәктәп эскәмиясеннән чыккан, аның үз белеме дә сай. Балага төпле белем бирүче укытучылар кирәк, – ди Казанда яшәүче Эльза Гомәрова.

Минзәлә районы укытучысы Гөлфинә Хамаева фикеренчә, хәзерге вакытта педкөллиятләргә институтка укырга керә алмаган, «3ле»гә укыган абитуриентлар бара.

– Өченче курста укыган студент мәктәптә укыта алмый. Анда бит программа шулкадәр авыр. Башлангыч сыйныф укытучысы булу өчен бар яктан да сәләтле, белемле булырга кирәк. Минем улым көллияттә физкультура укытучысына укый. Аны әле укучылар белән эшли ала дип әйтә алмыйм. Дөрес, укытучылар җитми, дибез. Әмма мәктәпкә теләсә кемне кертергә ярамый. Мин үзем ул яшьтә укыта алмас идем, – ди Гөлфинә Хамаева.

Студентларны мәктәпкә җибәрү мәгарифкә, киресенчә, зыян салмасмы? Бу хакта Арча педагогика көллияте директоры Гөлнара Гарипованың фикерен белештек.

– Бүген мәктәп, бакчаларда кадрлар кытлыгы зур. Шуңа күрә ничек тә булса мәгариф системасына ярдәм итәргә кирәк бит инде. Тагын нинди чыгу юлы бар? Элек тә укытучылар җитмәгән очракта соңгы курста белем алучы студентларны мәктәпләргә эшкә җибәргәннәр. Башлангыч сыйныф, физкультура укытучылары, музыка белгечләре җитмәгәндә, без дә мәктәпләргә ярдәм итәргә тырышабыз. Анда сәләтлеләрне җибәрәбез. Шуңа күрә начар булмас, дип уйлыйм. Бала укый да, эшли дә. Бу – аның өчен тәҗрибә. Киләчәктә хезмәт хаклары артып, вазгыять үзгәрмәсә, бүген кадрлар белән тәэмин итү бик авыр. Яңа мәктәпләр төзелә. Аларга белгечләр каян табарга? Шуңа күрә эшләп карыйк, – диде ул.

Сәрия МИФТАХОВА

Алсу МӨХӘММӘТОВА, Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгының матбугат хезмәте җитәкчесе:

– Быел 1500 белгеч мәктәпләргә эшкә урнашырга юллама алды. 2016 елдан Татарстанда кытлык булган фәннәрдән, бигрәк тә авыл җирлеге өчен әзерләнүче булачак укытучыларга ай саен 15 мең сум стипендия түләнә. Узган уку елында КФУда – 631, КФУның Алабуга институтында – 39, Чаллы педагогика көллиятендә 75 студент әлеге проектта катнашкан. Шуларның яртысы күптелле мәктәпләр программасы буенча белем ала. Узган ел 150 яшь укытучы эшкә урнаштырылса, быел 100дән артык «целевик» укучылар арасына киләчәк.
Авылларда «Мобиль укытучы» проекты эшли. Укытучыларга күрше мәктәпләргә йөреп укыту өчен район хисабыннан автомобильләр бирелә. Яшь укытучыларга республикада өч ел дәвамында ай саен 2510 сум өстәмә түләү каралган. Авылда, шәһәр тибындагы бистәдә яшәүче педагогларга ут, җылылык өчен коммуналь түләү чыгымнары кире кайтарыла. Кайбер районнарда яңа эшкә урнашкан белгечләргә бер мәртәбә түләүләр, эш урыныннан арендага торак бирү каралган.

Сан

Республикада 2020 елдан «Авыл укытучысы» («Земский учитель») федераль программасы тормышка ашырыла. Барлыгы 32 укытучы авылга күченгән. Быел тагын 23 укытучы авыл мәктәбенә кайтачак. Авылга кайтучы әлеге педагогларның барысына да берәр миллион сум акча бирелә. Тик шарты да бар. Килешү төзегәннән соң, алар шул мәктәптә биш ел эшләргә тиеш.

Эльвира ВӘЛИЕВА

ТҮРДӘН УЗЫГЫЗ!

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Анна Арахамия

Бер тәүлеге – җиде мең сум

Быелның беренче яртысына алынган саннарга караганда, Татарстан Идел буе федераль округына керүче төбәкләр арасында туристлар кабул итү буенча беренчелекне алган. Республикада 1,5 миллион чамасы кеше кунак булырга өлгергән инде. Сүз уңаеннан, әлеге күрсәткеч буенча без ил күләмендә дә алтынчы урында. Беренчелек – Мәскәүдә. Хәер, бу аңлашыла да. Ярты ел эчендә ил башкаласына 7 миллионнан артык турист килгән. Мәскәү өлкәсе, Краснодар крае, Ленинград өлкәсе һәм Санкт-Петербург та әлегә бездән алдарак. Идел буе федераль округына әйләнеп кайтсак, беренче өчлеккә керүче Башкортстан һәм Түбән Новгород өлкәсе дә эләккән. Ел башыннан аларның һәркайсы 860 мең чамасы туристны кунак иткән.

Татарстанга туристлар күбрәк Мәскәү, Мәскәү өлкәсе һәм Санкт-Петербургтан килә. Кунаклар бездә тәүлегенә уртача җиде мең сум акча сарыф итә. Бу хакта Татарстан Туризм буенча дәүләт комитеты җитәкчесе Сергей Иванов әйтте.

– Уртача исәпләүләргә караганда, республикага өч көнлек сәфәр 20 мең сум тирәсе тора. Дөрес, ялның сыйфатына карап, ул күбрәк тә, азрак та булырга мөмкин. Бездә төрле тәкъдимнәр бар, – диде ул.

Татарстанда туристлар барыннан да бигрәк Казан Кремленә ашкына. Былтыр, мәсәлән, кирмәндә 3,7 миллион кеше булган. Шулай ук Зөя шәһәр-утравы (1,3 миллион турист) һәм Изге Болгар (596 мең турист) да иң киң таралган юнәлешләр арасында. Шулай ук, Алабуга һәм Раифа монастырена карата да кызыксыну зур, ди белгечләр. Кунаклар күплегенә кунакханә һәм ресторан хуҗалары да сөенә: туристлар тоткан акча, ягъни уртача чек бәясе арткан. Шул ук «Татарстанстат» китергән саннарга караганда, быелның беренче чирегендә генә дә рестораторлар 15,6 миллиард сум керем алган. Бу узган елга караганда 19 процентка күбрәк.

Ашау-эчү, халыкның күңелен күрү – бер хәл, читтән килгән кешегә түбә дә тәкъдим итәргә кирәк бит әле.

– Билгеле сәбәпләр аркасында россиялеләргә карата виза сәясәте үзгәрде, чит илдә ял итү кыйммәтләнде. Нәтиҗәдә эчке туризмга сорау артты. Туристлар саны алдан фаразланганнан да күбрәк булып чыкты. Шуңа күрә кунакханәләрдә урын җитмәү мәсьәләсе калкып чыкты, – ди комитет рәисе Сергей Иванов. – Казанда да, шәһәрдән читтә дә туристларны урнаштыруга бәйле кытлык күзәтелә. Бүген инфраструктураны үстерү юнәлешендә эшлибез.

Туристларны таш дивардардан качып, табигатькә якынрак булырга өнди башладылар инде. Тик бу хакта соңрак. Әлегә исә туристлар «казан»ына әйләнеп кайтыйк.

«Тагын киләбез»

Татарстанда ял итүчеләргә ияреп «ВТ» хәбәрчесе дә Казан Кремленә юл тотты. Кирмән тирәсе Сабан туен хәтерләтә, билләһи. Җәйге яңгыр сибәләп торуына да карамастан, Казан Кремлендә алма төшәрлек тә урын юк.

– Безне мондый яңгыр белән генә куркытып булмый, «юеш» шәһәрдә яшибез, – ди Санкт-Петербургтан гаиләсе белән килгән турист Сергей Тихонов. – Җәйге ялны күңелле дә, файдалы да итеп үткәрәбез. Быел чит илгә чыгу мәшәкатькә әверелгәч, ил төбәкләре буйлап сәяхәт итәргә булдык. Татарстан – беренче тукталыш. Бер атнага дип килдек. Дусларым, танышларымнан Казан турында еш ишетә идем. Биредә яшәүчеләрнең кунакчыллыгы, гомумән, тарихка мөнәсәбәтегез шаккатырды. Моңарчы татарлар турында берни белмәсәм, хәзер татар телендә «рәхмәт» дип тә әйтә алам.

Төмәннән Диана белән Олегның исә Казанга беренче генә килүләре түгел.

– Казанга пандемиягә кадәр килгән идек. Бу юлы нәни кызыбыз Дианаңы да үзебез белән алдык, – ди алар. – Мәскәү һәм Санкт-Петербург белән чагыштырганда, монда бәяләр арзанрак. Казанның архитектурасы искиткеч. Монда шул кадәр чиста, ризыклар тәмле. Туганнарга Казаннан кучтәнәчкә «Татар халык ашлары китабы»н сатып алдык. Дүрт көн ял иттек. Иртәгә кайтып китәбез. Ял бик кыйммәткә төшмәде, чөнки кафе-рестораннарда бәяләр артык «тешләми», экскурсияләргә исә үзебез йөрдек. Без ялны алдан планлаштырып килдек. Монда юлны сорасаң да, аңлаталар, өйрәтәләр. Казанга тагын әйләнеп кайтырбыз әле.

Казан Кремлендәге бәяләрне без дә белештек. Биредәге кафеларның берсендә, мәсәлән, өчпочмак – 59, алма бөккәне 30 сум тора. Берне түгел, икене ашасаң да була. Ярты килолы чәкчәк – 339 сум. Бәясенә карап тормый, туристлар тәм-томны берничәне сатып ала. Казан Кремлендә туристларга нәрсә генә тәкъдим итмиләр: лалә чәчәге төшерелгән чынаяк – 500 сум, Казан мәчесе төшерелгән балалар оегы – 250 сум, милли бизәкле алка – 300 сум, каты тышлы Абдулла Алиш әкиятләре китабы – 840 сум. Киштәдә «Татар халык ашлары китабы»н да таптык, бәясе 700 сум тора.

Җәяүле ләззәт

Бер Казанда гына бикләнеп ятарга димәгән, әлбәттә. Сергей Иванов, Татарстанда үзебез өчен дә, кунаклар өчен дә кызыклы урыннар шактый, дигән фикердә.

– Кама Тамагы, Чистай, Алексеевск, Мамадыш, Арча, Кукмара буйлап сәяхәт һәр турист күңеленә кереп калачак, – ди Туризм буенча дәүләт комитеты җитәкчесе. – Бик матур табигатьле Кама Тамагында кунакханәләр дә, сыр заводы, хәтта виноград бакчасы да бар. Чистай исә үзенең музейлары һәм архитектура һәйкәлләре белән дан тота. Ул яңарыш та кичерә әле. Биредә кунакханәләр төзү һәм яр буен төзекләндерүгә бәйле берничә инвестиция проекты тормышка ашырыла. Алексеевск та – гаҗәеп район. Биләр үзе генә ни тора! Районда туку фабрикасы кебек тарихи биналар да, заманча ял үзәкләре дә бихисап. Мамадышка барырга да киңәш итәм. Биредә күпсанлы мәдәниятләр үзара бәйләнгән. Әлеге һәм башка районнар буйлап «Ялларда мең дә бер ләззәт» программасы буенча да сәяхәт итәргә мөмкин.

Күп кенә чит илләр ябык, кесә ягы чамалы булган шартларда, Татарстан... җәяүле ял да тәкъдим итә. Аптырамагыз, бу хәзер кәттә санала торган юнәлеш. Аның заманча сүзе дә бар. Татарстанда тел очыннан төшмәгән хейкингның (табигать кочагында кыска вакытка исәпләнгән җәяүле ял. – **Ред.**) берсе – ул «Идел буе сукмагы». Ульян өлкәсе чигеннән алып Чувашиягә кадәр сузылган әлеге юл республиканың 5 районын, Казанны һәм биредәге 12 паркны, 100дән артык мәдәни мирас объектын, 26 махсус саклана торган табигать территориясен берләштерә. Җәяүле юлның озынлыгы –

ТАТАРСТАНДА СЕЗ ӘЛЕ КҮРМӘГӘН УН УРЫН (республикадагы үзенчәлекле урыннарны яктыртып баручы блогер Русина Семененко тупланмасы)

- ✓**Экзотик урман** (Арча районы). Биредә маракуйя, папайя, гуава кебек җылы як җимешләре үсә, аларны татып карарга да мөмкин.
- ✓**«Урман һәм елга»** (Биектау районы). Глэмпинг көймәдә йөзәргә яратучыларга ошаячак.
- ✓**Олы Ачасыр авылы** (Яшел Үзән районы). Биредә чын авыл тормышы «кайный». Каюм Насыйри музее да бар.
- ✓**«Таң» ат клубы** (Лаеш районы). Монда атлар белән су коенырга да мөмкин, ди.
- ✓**«Идел буе сукмагы»** (бу проект турында яздык).
- ✓**Ленино-Кокушкино авылы** (Питрәч районы). Ленин яшәгән төбәктә музей-тыюлык урнашкан.
- ✓**Марал фермасы** (Яшел Үзән районы). Боланның бер төре булган мараллар зур урман эчендә яши. Ашарга, су эчәргә кешеләр янына чыгалар.
- ✓**Красновидово авылы** (Кама Тамагы районы). Идел ярындагы авыл биредә яшәгән билгеле шәхесләр белән дан тота.
- ✓**Зәңгәр күл** (Казан). Сулык Казансуны үстерү стратегиясе программасы ярдәмендә яңартылды. Фотога төшәргә яратучылар өчен күпер дә бар.
- ✓**Чатыр тау** (Азнакай районы). Тау итәгендә байбакларны да күрергә була.

СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРЛӘРГӘ СЕЛФИ ТӨШӘР ӨЧЕН БИШ ШӘП УРЫН

- **Кол Шәриф мәчете** (Казан)
- **Кукмара «каньоны»** (Кукмара районы)
- **Саескан тавы** (Лаеш районы)
- **Юрьев мәгарәсе** (Кама Тамагы районы)
- **Тихий Плёс авылы** (Югары Ослан районы)

350 чакрым. «Идел буе сукмагы»н быелның маенда тәкъдим иттеләр.

Чиләбедә яшәүче Сәрия һәм Дамир Гыйлаҗиевлар Казанга кунакка кайткан.

– Форсаттан файдаланып, тарихи сукмактан да уздык, – ди Дамир Гыйлаҗиев. – Без сәяхәт итәргә яратабыз. Татарстанда ел саен кунак булабыз. Изге Болгарны да, Зөя шәһәр утравын да күргәнебез бар инде. Бу юлы «Идел буе сукмагы»ннан йөрдек. Аны башыннан алып ахырына кадәр узу мәҗбүри түгел. Гид та кирәкми. Яңа проектның кесә телефоны өчен махсус кушымтасы бар. Шуны йөкләсәң дә юлга чыгып китәсең. Бик уңайлы. Без Югары Осланнан – Казанга, ә аннан Кама Тамагына кадәр бардык. Юлда кибетләр дә, кафелар да очрады. Ашыкмыйча гына сәяхәт итү өчен шәп ял.

Татарстан шәһәрләрен үстерү институтының Табигый территорияләрне һәм экотуризмны үстерү буенча дирекциясе җитәкчесе Оксана Саргина әйтүенчә, бер ай эчендә генә дә әлеге махсус кушымтаны 2,5 мең кеше йөкләгән. «Татарстан буйлап җәяү атларга теләүчеләргә Алабуганың «Түбән Кама» милли паркы, Арчаның Яңа Кырлае да кызыклы булачак», – ди Сергей Иванов.

Учак янындагы ял

Татарстанда ялның тагын бер заманча юнәлеше – глэмпинглар (табигать кочагында бөтен уңайлыклары булган ял. – **Ред.**) янгырдан соң тишелгән гөмбәләр кебек, зур тизлектә үсә. Бүген Татарстанның 15 районында һәм Казанда шундый 36 экотуризм объекты эшли. Ил күләмендә исә аларның саны 600 тирәсе дип исәпләнә. Билгеле булганча, экологик туризмны үстерүчеләргә дәүләт ярдәме каралган. Быелтыр илдә мондый капиталь булмаган кунакханәләр төзелешен субсидияләү программасы да гамәлгә керде. 2022 елда туристик мөмкинлекләре зур булган 20 төбәккә, шул исәптән Татарстанга 4 миллиард сумга якын акча бүлеп бирелде.

– Глэмпингларга коронавирус пандемиясе һәм аңа бәйле чикләүләр чорында ихтыяҗ артты, – ди Сергей Иванов. – Чикләр ябылу һәм эчке туризмны үстерүчеләргә дәүләттән ярдәм чаралары төзелешне тизләтте генә. Табигатьтә ял итәргә теләүчеләр һәрвакыт бар. Зур шәһәрләрдә яшәүчеләр арасында бигрәк тә. Бүгенге шау-шулы тормышта еш кына минут саен шалтырап торган телефонны бер читкә куеп, тынычлыкта каласы килә.

Питрәч районының Кощаково авылында урнашкан «Yurt Resort» глэмпингында хәләл ял тәкъдим итәләр.

– Без хәләл стандартлар буенча эшлибез, – ди глэмпингны оештыручы Римма Якупова. – Мәсәлән, өйдә эт белән яшәү, аракы рөхсәт ителми, мунча комплексы кеше күренмәслек итеп эшләнгән. Кунакларны хәләл ризыклар белән сыйлыйбыз. Шунысын да әйтик: безнең глэмпингта ял итүчеләрнең 80 проценты мөселман түгел. Алар бик зур рәхмәт әйтеп китәләр. Чөнки бездә тыныч. Туристлар гаиләләре, әби-бабайлары белән рәхәтләнеп ял итә. Хәзер сәламәт яшәү рәвеше алып баручылар да күп. Андыйлар кабул иттек. Туристлар өчен сигез тирмә, ун модуль йорт эшли. Аларда ак халатка кадәр бар да бар. Күзләрне ял иттерү өчен мәйданы 75 гектар тәшкил иткән күл, ылыслы урман, кыш көне дә катмый торган елга да бар. Якын арада һава алмашы үзенчәлеле булган тирмә-мунча, мондый корылмалар ил күләмендә дә берничә генә, һәм тирмә-ресторан ачарга телибез, – ди эшкуар.

Яшел Үзән районының Прибой авылындагы глэмпингта исә туристларга чын авыл тормышын тәкъдим итәләр.

– Кечкенәдән хайваннар яратам. Туризм белән шөгыльләнү дә хыялым иде, – ди «Прибой» глэмпингын оештыручы Илдар Гариев. – Биредә чын авыл тормышын күрергә мөмкин. Бүген шәһәрдә яшәүче балалар арасында йорт хайваннарын бер тапкыр күрмәүчеләр дә җитәрлек. Бездә исә фермада малларны сыйпарга, яңа туган бозауларны шешәдән ашатырга, атта йөрергә мөмкин. Кунакларны үзебез җитештергән экологик чиста ризык белән сыйлыйбыз. Федераль трассага якын урнашканлыктан, безгә еш кына Мәскәү, Түбән Новгородтан Казанга баручылар да хәл җыярга дип керә. Бүген кеше авыл тормышына сусаган.

Зөя елгасы ярындагы Тихий Плёс авылында 2010 елда Сергей Безруков катнашында төшерелгән кино өчен махсус төзелгән ярым җимерек хәлдәге арка бар. Фото төшәргә яратучылар әнә шуны үз итә.

кешеләр хәмерле ял турында уйламый да. Мондый ял тәрбия ягыннан да бик яхшы. Чөнки бала әти-әнисеннән күреп өйрәнә.

Римма Якупова әйтүенчә, аларга чит илләрдән дә ял итәргә киләләр.

– Татарстаннан тыш, Мәскәү, Санкт-Петербург, Белгород, Уфа, Самара, Барнаул кебек шәһәрләрдән килүчеләр бар. Хәләл булгач, Төркия, Согуд Гарәбстаны, Малайзия кебек чит илләрдән дә кунаклар кабул иттек.

Әлеге ял үзәгендә алты кешелек агач йортта дүртәү яшәүнең бер тәүлеге эш көннәрендә – 7 мең сум, ялларда исә 9 мең сум тора. Кунаклар күбрәк булса, һәр кеше өчен өстәп 1 мең сум түлисе. Атта йөрү, мунча керү дә түләүле. Мәсәлән, ферма буенча экскурсиянең бер сәгате 1 мең сум тора.

Глэмпинглар кесәгә суга, дип тел шартлатырга ашыкмагыз. Татарстан Туризм буенча дәүләт комитеты җитәкчесе фикеренчә, мондый ял арзан тора да алмый.

– Сез бит табигать кочагында ял итәсез. Монда, гадәттә, инженер челтәрләре дә, эшче көчләр дә юк. Аның каравы сыйфатлы ял өчен бөтен мөмкинлекләр дә тудырыла. Шәһәр үзәгендә һәм биек тау башында бер чынаяк каһвә бер бәя тормый, – диде Сергей Иванов.

vk.com

ТАТАРСТАНГА КИЛГӘН ТУРИСТЛАР

- 2019 ел – 3,6 миллион кеше
- 2020 ел – 1,9 миллион кеше
- 2021 ел – 3,3 миллион кеше
- 2022 ел – 3,9 миллион кеше

«Татарстанда яшәүчеләрне ял итәргә өйрәтәсе иде»

Бай тарихлы һәм кунакчыл Татарстан туристларны нәрсә белән шаккатыра? Бу хакта экскурсовод, Татарстанда кунакчыллык илчесе Раушания МИҢНУЛЛИНА белән сөйләштек.

:: Татарстанга туристлар кайдан килә, аларны нәрсә кызыксындыра?

– Безгә дөньяның төрле почмакларыннан киләләр. Кубесенең безгә беренче генә килүе дә түгел. Шуңа күрә таләпләре үзгә. Без белмәгән Татарстанны күрсәтегез әле, диләр. Мәсәлән, бу атнада Мәскәүдән килгән бер төркем Казанда моннан егерме ел элек булган. Шушы вакыт аралыгында булган үзгәрешләрне күрәселәре килә. Гел шаккатырырга туры килә, кыскасы. Татарстанга килергә яраталар, чөнки бездә яшәү өчен бөтен шартлар да бар, диләр. Барыннан да бигрәк, Казан Кремлен күрергә телиләр. Иске Татар бистәсе үзенең миллилеге, татар халкының гореф-гадәтләре белән җәлеп итә. Музейларыбыз да бик эчтәлекле. Изге Болгарга экскурсиядән шаккатып кайталар. Зөя шәһәр-утравының архитектурасы, табигате бик матур. Соңгы арада Зәңгәр күлгә карата кызыксыну да артты. Белгеч буларак мин моны бик үк хуплап та бетермим. Чөнки кеше күп йөри башлагач, биредәге табигый байлык – зәңгәр балчык юкка чыгарга мөмкин. Табигатьне саклау турында да онытмасак иде.

:: Тармакка нәрсә җитми?

– Су юлы безнең өчен авырткан җир булып тора. Мәсьәләне хәл итү юнәлешендә эшлиләр, билгеле. «Татфлот» төзелде. Судноларны яңарталар. Хәзер су юлыннан Чувашиягә кадәр сәяхәт итәргә мөмкин. Казансу буенча да экскурсияләр саны артты. Тик кыенлыклар бар әле. Мәсәлән, су юлы буйлап Зөя шәһәр-утравына яки Изге Болгарга бару-кайту өчен билетны өч көн алдан иртә таңнан кассада чират торып сатып алырга кирәк. Әле анда да бер кулга биш билет кына бирәләр. Туристның кәефен кыра торган күренеш бит бу. Метеорлар саны артуын, билетларны онлайн сатуны җайга салуларын көтәбез. Җәй көне су юлыннан сәяхәт итәсе килә бит.

:: Татарстанга килгән турист ул нинди?

– Акчалы кеше. Аларга ялның сыйфаты мөһим. Чөнки элек чит илгә сәяхәт иткәннәр, хәзер безгә киләләр. Берничә ел элек Татарстанга туристлар өч-дүрт көнгә килсә, хәзер берәр атна торалар. Шуңа күрә гел экскурсияләрдә генә йөрмичә, ялның төрлесен сынап карыйлар. Татарстанда сәяхәт итәр өчен урыннар бихисап. Республикада яшәүчеләрне дә ял итәргә өйрәтәсе иде. Ни өчендер бездә андый гадәт юк. Мәктәп укучыларына Казан артын бик тә күрсәтәсебез килә. Юлга чыккач, тарихын да сөйлисең, табигате белән дә таныштырасың бит аның. Югыйсә бүген ватанпәрвәрлек турында күп сөйләшәбез. Без – горурланырлык халык. Татарстанга килгән туристлар, сездә бик чиста, дип гаҗәпләнәләр. «Нефть өстендә утырасыз шул», – дип төрттерергә тырышучылар да бар. Пөхтәлеккә омтылуның «кара алтын»га бернинди катнашы юк. «Җыештыручылар кайда соң?» – дип сораучыларга: «Без урамнарны чүпләмибез», – дип җавап бирәм. Кәнфит ашадың икән, кәгазен кесәгә йә сумкага салып тор да, чүплек очрагач, шунда ташла бит инде. Кайберәүләр өчен бу – ят күренеш. Хәзер Бауман урамында тәмәке тартучылар да нигездә туристлар гына. Бездән: «Татарларны яраттык», – дип китәләр.

24 июль | Дүшәмбе

ВГТРК ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 16+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «БЕР-БЕР ХӘЛ». Телевизион нәфис фильм 16+
09.00, 16.30 «ЫШАНАСЫ КИЛӘ». Телесериал 16+
10.00, 23.00 «ШИРОКА РЕКА». Телесериал (Россия) 16+
11.00 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
11.30, 21.00 «Заман көзгесе» 6+
12.00, 22.00 «ЧЕМПИОННАР ӘНИЛӘРЕ». Телесериал 16+
13.00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 16+
14.00 «Соотечественники» 16+
14.45 «Музыкаль мәйдан» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә». «Акыл батл» 0+
16.00 «Переведи!» (учим татарский язык) 6+
17.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 16+
18.00 «Прямая связь» 16+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00 «Туган авылым» 12+
20.15 «Кучтәнәч» 0+
00.00 «Соотечественники». Альбина Шагимуратова. Примадонна Востока и Запада 16+
00.25 «Каравай». Красота национального костюма 6+
00.50 «Таяну ноктасы» 16+
01.15 «КВН РТ-2022» 16+
02.05 «БЕР-БЕР ХӘЛ». Телевизион нәфис фильм 16+
02.30 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 16+
03.55 «Аулак өй» 6+
04.45 «Точка опоры» 16+
05.35 «Оныта алмыйм…» Ретро-концерт 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06/00, 13.05, 01.00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 16+
08.00 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.40, 18.20, 23.10, 04.20 «Башваткыч» 12+
09.50 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 16+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30 «Туган җир» 12+
12.05 «Йөрәктән – йөрәккә». Фердинанд Сәлахов турында телеочерк 16+
15.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә… 6+
16.30 «Бөркет канатында хөрлек бар». Язучы Адлер Тимергалин турында телеочерк 16+
17.30 «Яшьләр тукталышы» 6+
19.10, 22.15 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
19.30 «Калеб» 6+
20.00 «Заман көзгесе» 6+
20.30, 02.35 «Таяну ноктасы» 16+
21.25 «Әниемнең җылы кочагы» 16+
00.15 «Йөрәктән – йөрәккә». Марсель Әхмәтҗанов турында телеочерк (субтитрлы) 16+
03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.25 «Йөрәктән – йөрәккә». Фердинанд Сәлахов турында телеочерк (субтитрлы) 16+
05.10 «Әй, язмыш, язмыш…» 16+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
16.00 «Мужское/Женское» 16+
16.50 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.30 Информационный канал 16+
19.55 «Куклы наследника Тутти» 16+
21.00 «Время»
22.00 Агния Дитковските, Александр Устюгов в многосерийном фильме «МИССИЯ «АМЕТИСТ» (S) 16+
23.00 «Большая игра» 16+
00.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «АстроУмные» 16+
00.40 ПОДКАСТ.ЛАБ «Собрались с мыслями» 16+
01.20 ПОДКАСТ.ЛАБ «Свидетели Эйзенштейна» 16+
02.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «Обязательно к прочтению» 16+
02.35 ПОДКАСТ.ЛАБ «20 лет спустя» 16+
03.00 Новости
03.05 ПОДКАСТ.ЛАБ «20 лет спустя» 16+
03.20 ПОДКАСТ.ЛАБ «Не лыком шиты» 16+
03.55 ПОДКАСТ.ЛАБ «Легкие деньги» 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 Сергей Маковецкий, Александр Яценко, Татьяна Лялина, Виктор Сухоруков, Артур Иванов, Мария Шумакова, Константин Крюков, Артём Ткаченко, Мария Палей, Юрий Колокольников, Игорь Миркурбанов, Виктор Добронравов, Виталий Хаев, Владимир Стеклов, Леонид Кулагин, Владимир Симонов, Людмила Полякова, Никита Панфилов, Антон Батырев, Юрий Батурин. «ГРОЗНЫЙ» 16+
16.30 «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Премьера. Евгений Сидихин, Лариса Шахворостова, Александр Самойленко, Зоя Бербер, Александр Голубев, Илья Антоненко, Алёна Коломина, Дарья Повереннова, Валентин Смирнитский, Анна Якунина. «СЧАСТЬЕ НЕ ЗА ГОРАМИ» 16+
23.30 Сергей Маковецкий, Евгений Ткачук, Дарья Урсуляк, Тимофей Трибунцев, Никита Ефремов, Александр Яценко. «ТИХИЙ ДОН» 12+
01.05 Анастасия Веденская, Сергей Губанов, Сергей Рудзевич, Виолетта Давыдовская, Любовь Германова. «РАЯ ЗНАЕТ ВСЁ!» 12+

МАТЧ ТВ

06.00, 14.25 «Кто кого?» 12+
06.30 «Всё о главном» 12+
07.00, 12.55, 14.55 Новости
07.05, 15.30, 21.30, 00.00 Все на Матч! Прямой эфир
08.55 Футбол. Чемпионат мира. Женщины. Италия – Аргентина. Прямая трансляция из Новой Зеландии
11.00 «География спорта. Таджикистан» 12+
11.30 Смешанные единоборства. UFC. Том Аспинэлл против Марчина Тыбуры. Трансляция из Великобритании 16+
12.35 Специальный репортаж 12+
13.00 «Есть тема!» Прямой эфир
15.00 Автоспорт. Ралли-рейд «Шёлковый путь» 0+
16.00 «ПЕЛЕ: РОЖДЕНИЕ ЛЕГЕНДЫ» 12+
18.15 «Громко». Прямой эфир
19.25 Футбол. МЕЛБЕТ-Первая Лига. «Химки» (Московская область) – «Торпедо» (Москва). Прямая трансляция
22.00 Дартс. Профессиональная лига. Про Тур 5. Прямая трансляция из Москвы
00.55 Футбол. Чемпионат Бразилии. «Коритиба» – «Флуминенсе». Прямая трансляция

НТВ

05.00 Сериал «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 Сериал «ЛЕСНИК» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 Сериал «СКОРАЯ ПОМОЩЬ» (S) 16+
16.45 Премьера. Сериал «ЗИМОРОДОК» (Турция) (S) 16+
20.00, 00.00 Детектив «МЕНТОВСКИЕ ВОЙНЫ» (S) 16+
00.20 «Основано на реальных событиях» 16+
01.20 Детективный сериал «ДИКИЙ» 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «6 кадров» 16+
06.35 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.00 «Давай разведёмся!» 16+
09.00 «Тест на отцовство» 16+
11.15 «Понять. Простить» 16+
12.30 «Порча». «Спасите мою маму» 16+
13.00 «Знахарка» 16+
13.35 «Верну любимого» 16+
14.05 «Голоса ушедших душ» 16+
14.40 «Преступления страсти» 16+
19.00 «КОГДА УМРЁТ ЛЮБОВЬ» 16+
23.00 «Понять. Простить» 16+
00.15 «Порча» 16+
00.45 «Знахарка» 16+
01.10 «Верну любимого» 16+
01.35 «Голоса ушедших душ» 16+
02.00 «ОБЪЯТИЯ ЛЖИ». 1-я – 4-я серии 16+
05.05 «6 кадров» 16+

ЗВЕЗДА

06.00 «Хроника Победы». Документальный сериал 16+
06.35, 09.15 «ДАУРИЯ» 12+
09.00, 13.00, 19.00 Новости дня. 16+
11.05, 13.25 «ОТРАЖЕНИЕ». Телесериал. 1-я - 6-я серии 16+
18.10 «Неизвестные сражения Великой Отечественной». Документальный сериал. «Защищая «Ворота Кавказа» 16+
19.55 «Загадки века с Сергеем Медведевым». Документальный сериал 12+
23.15 «ДОМ, В КОТОРОМ Я ЖИВУ» 12+
01.10 «СПАС ПОД БЕРЕЗАМИ» 16+
03.15 «ПО ДАННЫМ УГОЛОВНОГО РОЗЫСКА…» 12+

25 июль | Сишәмбе

ВГТРК ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 16+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «БЕР-БЕР ХӘЛ». Телевизион нәфис фильм 16+
09.00, 17.00 «ЫШАНАСЫ КИЛӘ». Телесериал 16+
10.00, 23.00 «ШИРОКА РЕКА». Телесериал 16+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте» 16+
11.15 «Память сердца» 16+
11.30 «Гаилә учагы» 16+
12.00, 22.00 «ЧЕМПИОННАР ӘНИЛӘРЕ». Телесериал 16+
13.00 «Туган җир» 12+
13.30 «Юлчы» 16+
14.00 «Путь» 16+
14.15 «Не от мира сего…» 16+
14.45 «Музыкаль мәйдан» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Төймә» 0+
16.00 «Соотечественники» 16+
16.30 «Болгар радиосы» концерты 16+
18.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 16+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00 «Туган авылым» 12+
20.15 «Кучтәнәч» 0+
21.00 «Ватандашлар» 16+
00.00 «Видеоспорт» 16+
00.25 «Каравай». Хромка живая старина 6+
00.50 «Соотечественники». Сердечная команда Рената Акчурина 16+
01.15 «КВН РТ-2022» 16+
02.05 «БЕР-БЕР ХӘЛ». Телевизион нәфис фильм 16+
02.30 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 16+
03.55 «Аулак өй» 6+
04.45 «Точка опоры» 16+
05.35 «Оныта алмыйм…» Ретро-концерт 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.00 «Манзара». Мәгълүмати- күңел ачу программасы 16+
08.00 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.40, 18.20, 23.10, 04.20 «Җырлыйк әле!» 12+
09.40 «Татар сүзе» 12+
10.30 «Заман көзгесе» 6+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30 «Нәсыйхәт» 16+
12.05, 21.25 «Ком сәгате» 16+
15.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә… 6+
16.30 «Таяну ноктасы» 16+
17.00 «Йөрәктән – йөрәккә». Гөлзада Сафиуллина турында телеочерк (субтитрлы) 16+
19.10 «Татар әдәбияты дәресләре» 6+
20.00 «Халкым минем» 12+
20.30, 02.35 «Таяну ноктасы» 16+
22.15 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
00.15 «Тамчы-шоу» 6+
00.40 «Ватандашлар» 16+
03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.25 «Сәхнә юлы салган чишмә җыры». Татарстанның халык артисты Рауза Хәйретдинова турында телеочерк 16+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
16.00 «Мужское/Женское» 16+
16.50 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.30 Информационный канал 16+
19.55 «Куклы наследника Тутти» 16+
21.00 «Время»
22.00 «МИССИЯ «АМЕТИСТ». Многосерийный фильм (S) 16+
23.00 «Большая игра» 16+
00.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «Жизнь замечательных» 16+
00.40 ПОДКАСТ.ЛАБ «Кот Шрёдингера» 16+
01.20 ПОДКАСТ.ЛАБ «Антропология» 16+
02.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «Неформат» 16+
02.35 ПОДКАСТ.ЛАБ «Анекдоты» 16+
03.00 Новости
03.05 ПОДКАСТ.ЛАБ «Анекдоты» 16+
03.20 ПОДКАСТ.ЛАБ «Креативные индустрии» 16+
03.55 ПОДКАСТ.ЛАБ «Гори огнем» 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 Сергей Маковецкий, Александр Яценко, Татьяна Лялина, Виктор Сухоруков, Артур Иванов, Мария Шумакова, Константин Крюков, Артём Ткаченко, Мария Палей, Юрий Колокольников, Игорь Миркурбанов, Виктор Добронравов, Виталий Хаев, Владимир Стеклов, Леонид Кулагин, Владимир Симонов, Людмила Полякова, Никита Панфилов, Антон Батырев, Юрий Батурин. «ГРОЗНЫЙ» 16+
16.30 «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Премьера. Евгений Сидихин, Лариса Шахворостова, Александр Самойленко, Зоя Бербер, Александр Голубев, Илья Антоненко, Алёна Коломина, Дарья Повереннова, Валентин Смирнитский, Анна Якунина. «СЧАСТЬЕ НЕ ЗА ГОРАМИ» 16+
23.30 Сергей Маковецкий, Евгений Ткачук, Дарья Урсуляк, Тимофей Трибунцев, Никита Ефремов, Александр Яценко. «ТИХИЙ ДОН» 12+
01.05 Анастасия Веденская, Сергей Губанов, Сергей Рудзевич, Виолетта Давыдовская, Любовь Германова. «РАЯ ЗНАЕТ ВСЁ!» 12+

МАТЧ ТВ

06.00, 14.25 «Кто кого?» 12+
06.30 «Наши иностранцы» 12+
07.00, 10.00, 14.55 Новости
07.05, 15.30, 00.30 Все на Матч! Прямой эфир
10.05 Специальный репортаж 12+
10.25, 01.50 «Спортивный век» 12+
10.55 Футбол. Чемпионат мира. Женщины. Швейцария – Норвегия. Прямая трансляция из Новой Зеландии
13.00 «Есть тема!» Прямой эфир
15.00 «Магия большого спорта» 12+
16.00 «Шёлковый путь. Новейшая история». Документальный фильм 12+
17.00 Футбол. МИР Российская Премьер-Лига. Обзор тура 0+
18.00 Футбол. FONBET Кубок России. «Пари НН» (Нижний Новгород) – «Динамо» (Москва). Прямая трансляция
20.30 Футбол. FONBET Кубок России. «Зенит» (Санкт-Петербург) – «Ахмат» (Грозный). Прямая трансляция
23.30 Дартс. Профессиональная лига. Про Тур 5. Прямая трансляция из Москвы
01.20 Футбол. Чемпионат мира. Женщины. Обзор 0+
02.20 «Что по спорту? Санкт-Петербург» 12+
02.50 Новости 0+

НТВ

04.50 Сериал «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 Сериал «ЛЕСНИК» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 Сериал «СКОРАЯ ПОМОЩЬ» (S) 16+
16.45 Премьера. Сериал «ЗИМОРОДОК» (Турция) (S) 16+
19.00 «Сегодня»
20.00, 00.00 Детектив «МЕНТОВСКИЕ ВОЙНЫ» (S) 16+
00.20 «Основано на реальных событиях» 16+
01.20 Детективный сериал «ДИКИЙ» 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
07.55 «Давай разведёмся!» 16+
08.55 «Тест на отцовство» 16+
11.10 «Понять. Простить» 16+
12.25 «Порча». «Возлюбленная» 16+
12.55 «Знахарка» 16+
13.30 «Верну любимого» 16+
14.05 «Голоса ушедших душ» 16+
14.40 «Преступления страсти» 16+
19.00 «СЛАБОЕ ЗВЕНО» 16+
23.30 «Понять. Простить» 16+
00.40 «Порча» 16+
01.05 «Знахарка» 16+
01.30 «Верну любимого» 16+
01.55 «Голоса ушедших душ» 16+
02.20 «ОБЪЯТИЯ ЛЖИ». 5-я – 8-я серии 16+ .

ЗВЕЗДА

06.15 «КАДЕТЫ». Телесериал. 3-я и 4-я серии 12+
09.00, 13.00, 19.00 Новости дня 16+
09.15 «ОПАСНЫЕ ГАСТРОЛИ» 12+
11.05, 13.25 «ОТРАЖЕНИЕ». Телесериал. 7-я – 12-я серии 16+
18.10 «Неизвестные сражения Великой Отечественной». Документальный сериал. «Прорыв «Голубой линии» 16+
19.55 «Улика из прошлого» 16+
23.15 «ИХ ЗНАЛИ ТОЛЬКО В ЛИЦО» 12+
01.05 «СПАС ПОД БЕРЕЗАМИ». Телесериал. 4-я – 6-я серии 16+
03.10 «ОПАСНЫЕ ГАСТРОЛИ» 12+
04.35 «Афганский дракон». Документальный фильм 12+

Кайда күпме?

Республика кырларында урып-җыю эшләре дәвам итә. 90 мең тоннага якын уңыш җыеп алынган. Бу – Татарстан Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының 20 июльгә мәгълүматлары.

Район	Суктырылган, ашлык, тоннада	Уңдырышлылык ц/га
Азнакай	58	12,7
Аксубай	12221	29,9
Актаныш	626	19,6
Алексеевск	2900	28,3
Әлки	12190	30,7
Әлмәт	401	14,0
Апас	2199	23,5
Балтач	573	25,8
Буа	7566	33,9
Биектау	377	19,8
Чүпрәле	641	34,6
Зәй	15338	33,5
Кама Тамагы	1742	29,0
Лаеш	591	35,3
Мамадыш	1973	37,4

Район	Суктырылган, ашлык, тоннада	Уңдырышлылык ц/га
Минзәлә	2375	26,5
Мөслим	208	21,9
Түбән Кама	3690	21,7
Яңа Чишмә	5398	30,9
Нурлат	5015	37,0
Питрәч	660	50,8
Балык Бистәсе	872	25,7
Саба	561	31,7
Сарман	4564	22,5
Спас	3181	30,7
Тәтеш	300	57,7
Тукай	555	18,7
Чистай	1110	27,8
Ютазы	85	17,0
Татарстан	87971	29,6

КОТЛЫЙБЫЗ!

Законлылыкны ныгытуга, гражданнарның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклауга зур өлеш кертүе, күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасы Югары Суды судьясы **Абдуллина** Гөлнара Әсхәт кызы; һөнәр берлекләре хәрәкәтен үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Татарстан Республикасы Һөнәр берлекләре федерациясе» берлеге бүлек башлыгы – хезмәт буенча баш техник инспекторы **Андина** Ирина Васильевна; финанс-икътисад эшчәнлегендәге казанышлары һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Финанс идарәсе» муниципаль казна учреждениесе исәп һәм хисап бүлеге башлыгы **Искәндәрова** Тамара Дмитриевна; республиканың агросәнәгать комплексын үстерүгә өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен; «Алан» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте механизаторы (Татарстан Республикасының Теләче районы) **Касыймов** Наил Камил улы; республикада автомобиль спортын популярлаштыруга зур өлеш кертүе һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен «Татарстан Республикасының Автомобиль спорты федерациясе» төбәк иҗтимагый оешмасы техник директоры **Мортазина** Резеда Әнәс кызы; халыкка югары культуралы хезмәт күрсәтүне тәэмин итүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен «Казан шәһәренең азык-төлек һәм социаль туклану департаменты» акционер җәмгыяте генераль директорының беренче урынбасары **Солтанова** Ильмира Рафис кызы **Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

* * *

Югары дәрәҗәдәге һөнәри осталыгы, республиканың дәүләт хакимияте органнарында күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасы Рәисенең Документлар белән тәэмин итү һәм контроль идарәсе контроль бүлеге мөдире **Мәрданшин** Руслан Мөҗип улы **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

Динә
ГЫЙЛАҖИЕВА

ТЕШЛӘП КЕНӘ КАЛМЫЙ

Күтеп алган җәй еш кына үзәккә үткән черкиләре белән дә истә кала. Тынычлап эшләргә дә, ял итәргә дә ирек бирми алар. Черки тешләгән урын кычытып кына калса ярый да. Белгечләр кисәтә: черкиләр чир дә таратырга мөмкин.

Табиб-терапевт Гөлназ ШӘЙДУЛЛИНА черкиләр турында ишетергә туры килгән кайбер имеш-мимешләргә ачыклык кертте.

Черки тешләүнең бер зыяны да юк. Черки тешләүдән куркырга кирәкми. Әмма алар тешләгән урынны кашысаң, инфекция эләгеп, эшләр зурга китәргә мөмкин. Черки тешләгән урын бик озак төзәлмәсә, үлекләсә, шешеп чыкса, 3–4 көн эчендә кычыту бетмәсә, кичекмәстән табибка мөрәҗәгать итәргә кирәк. Черки тешләгәннән соң тын кысылса, күкрәк читлеге авыртса, тиз арада белгечкә күренү хәерле. Гадәттә, черки күз яки каш тирәсен тешләгәндә шулай була.

Вируслы авырулар тарата. Черки тарата алган бердәнбер куркыныч чир – малярия. Алар вируслы авырулар таратмый. Әйтик, грипп белән авырган кешене тешләгән черки соңрак икенче берәүгә һөҗүм итсә дә, бу чир аңа йокмаячак. Черкиләр кешедән кешегә СПИД, гепатит йоктыра икән, дигән сүзләр дә дөреслеккә туры килми.

Черки тешләгәннән соң, кеше үләргә дә мөмкин. Беренче карашка арттыру кебек тоелса да, бу сүзләрдә хаклык бар. Черкинең сәләгә организмга эләккәч, кайбер кешедә аллергия башланырга мөмкин. Ул өч төрле стадиядә уза ала. Җиңелчә генә аллергия вакытында черки тешләгән урын шешеп, кызарып чыга, кешенең температурасы да күтәрелергә мөмкин. Бу халәт 10–14 көн чамасы дәвам итә. Черки тешләүгә аллергиясе булган кешенең тәнен кычыткан чаккан кебек вак тимгелләр дә баса ала. Андый вакытта кеше анафилактик шок кичерә ала. Ул, тыны кысылып, буыла башларга да мөмкин. Тиз арада ярдәм итәргә өлгермәсәләр, черки тешләүнең, дөрестән дә, үлем-китем белән тәмамлану куркынычы бар.

Черкиләр кан төркеме беренче булган, артык авырлыктан интеккән яки исерткеч эчемлек кулланган кешеләрне ярата. Черкиләр кеше аермый. Аларга кемне тешләүләре мөһим түгел. Черкиләр кан, кан тамырлары җылысына килә. Бар да шуңа бәйле. Әгәр кешенең кан тамырлары тирәндә урнашкан яки тиренең май катламы бик калын икән, бу бөҗәкләр аларны читләп үтәргә дә мөмкин. Сүз уңаеннан, артык авырлыктан интеккән, йөкле хатын-кызлар еш кына черки тешләүгә чыдап булмый дип зарлана. Моңа да гаҗәпләнәсе юк. Аларның тән тиресе әйләнә-тирәлеккә бик күп җылылык бүлеп чыгара. Черкиләр әнә шуңа җыела да.

Үзем сынадым

ЧЕРКИДӘН САКЛЫЙ

Черкидән саклануның бик җайлы ысулын таптым бит әле. Үсемлек мае, 9 процентлы аш серкәсе һәм шампуньне бертигез күләмдә алып болгатам да шуны тәннең ачык урыннарына сылыйм. Черкиләрдән көн буе саклый. Йоклар алдыннан гына юып төшерәм.

Алсу ВӘЛИЕВА. Әлмәт

vk.com

Черки тешләсә, ни эшләргә?

✓ Черки тешләгән урынны зарарсызландыручы чара (спирт, йод, зеленка, хлоргексидин һ.б.) белән эшкәртегез.
✓ Тешләнгән урынны кашырга ярамый.
✓ Кычытуны басу өчен, черки тешләгән урынга суга нашатырь спирты кушып ясалган катнашма яки черкиләргә каршы махсус крем сөртегез, спрей сиптерегез. Боз куеп торуның да файдасы булачак. Алоэ, әрем, бөтнек яфраклары да кычытуны баса.
✓ Урамга, табигатькә чыкканда киемгә, тәнгә черкиләргә каршы махсус препарат сиптерегез.
✓ Канэчкечләр өйгә кермәсен өчен, тәрәзәгә – москит челтәре, бүлмәләргә бу бөҗәкләрне куркыта торган фумигатор, махсус спиральләр куегыз.

Черкиләр тир исеннән курка. Киресенчә, черкиләр тир исенә җыела. Шуңа күрә чамадан тыш нык тирли торган (гипергидрозлы) кешеләргә җәен аеруча авырга туры килә. Канэчкечләр һөҗүменнән саклану өчен, җәен даими рәвештә юынып торырга кирәк.

Тәрәзә төбенә лавр яфрагы, лаванда, рәйхан (базилик), яран гөл утыртсаң, өйгә черки кермәячәк. Алар шушы үсемлекләр утырган тәрәзә төбенә генә килмәячәк. Исләре көчле булса да, әлеге гөлләр бөтен өйне черкидән саклап бетерә алмый.

Файдасы тисен

Герпес үзәккә үтсә...

Салкын тигәннән соң, еш кына ирен чабыра. Аннан берничә ысул ярдәмендә котылырга мөмкин.

1 Мамыкны 1,5 процентлы сөткә манып, герпес чыккан урынга тидерергә кирәк. Сөтне юмагыз, кипкәнче тотыгыз. Ашарга, эчәргә дә ярамый. Процедураны 2–3 сәгать саен кабатларга кирәк. Кичкә герпесның эзе генә калачак.

2 Татлы тамыр (солодка) шулай ук герпеска каршы яхшы чара булып тора. Аны порошок итеп изәргә, шуңа кайнар су өстәргә кирәк. Куе ботка халәтенә җиткәч, герпес чыккан урынга сөртәсе булачак. Моны төнгә каршы, йоклар алдыннан эшләп, иртән юып алырга кирәк.

3 Герпес кабарып чыкса, водород перекисен 2–3 сәгать саен сөртегез. Кичкә инфекция беткән булыр.

4 Бер тырнак сарымсакны изеп, герпес чыккан урынга куйсагыз, ярдәме тими калмас.

5 Бөтнекнең эфир маен герпеслы урынга сөртсәгез, ул тиз арада юкка чыгар. Моны көнгә өч тапкыр эшләргә кирәк.

6 Һәр ике сәгать саен алоэ согын чабырган урынга сөртсәгез, шулай ук ярдәм итәр. Алоэ яфрагын ярып, авырткан җиргә кую да файдалы.

Белеп тор!

✓ Әгәр йөткерү йокларга ирек бирми икән, тел астына аз гына тоз кабып, суырып торыгыз. Балаларга тозлы ипи бирергә мөмкин. Йөткерү бетәчәк.
✓ Очкылык тотып интексәгез, бер кашык шикәр комы кабып куегыз яисә тел очына горчица тидерегез.
✓ Сару кайнаудан интеккән кешегә балан кайнатмасы ярдәмгә килер. Моның өчен бер стакан кайнар суга бер чәй кашыгы кайнатма болгатып эчегез.

Киңәш-табыш

БАВЫРГА ШИФА

1 аш кашыгы киптереп вакланган каен яфрагын 500 мл кайнар суга салып, ярты сәгать төнәтергә һәм сөзәргә кирәк. Шуны көненә 5–6 тапкыр, 50шәр мл күләмендә эчәсе. Бу төнәтмә лямблиоз, бавыр авыруыннан, салкын тигәннән файдалы.

КУЛЛАР МАТУР БУЛСЫН

1 литр җылы суга 2 аш кашыгы тоз салып эретергә кирәк. Иң элек кулларны җылы суга тыгып, 10 минут тотасы булачак. Аннары 1 йомырка сарысына 1әр аш кашыгы бал һәм үсемлек мае кушып, кулларга шушы катнашманы сөртеп, 20 минут тотарга. Әлеге ысул кулларны йомшарта, ярылганланган урыннарны 3–4 көндә төзәтә.

Абау!

БӘРӘҢГЕ ПАРЫ ЗАРАРЛЫ

Томау, ютәл борчыганда, күпләр бәрәңге пары ярдәмендә дәвалана. Эссе пар тыгылган борынны ача, тын алу да җайланып китә. Беренче карашка кешенең шундук хәлен җиңеләйткән бу алым чынлыкта сәламәтлеккә зур зыян салырга мөмкин, дип кисәтә белгечләр. Баксаң, ул тын юлларының ялкынсынуына китерә.

Бәрәңге пары сулыш әгъзалары тукымаларына үтеп керә алмый һәм аның организм өчен файдалы матдәләре дә юк. Ул шулай ук микроблар белән дә көрәшми, ди алар. Иң куркынычы – бәрәңге парында утырган кешедә бронхит барлыкка килү ихтималы да бар икән.

Бәрәңге парының температурасын белеп булмый. Ул бик кайнар булып, тавыш ярыларына зыян салырга мөмкин. Кайнар бәрәңге пары йөткерүне, тамакны пешереп, анда шеш барлыкка килергә, сулыш алу, селәгәй бүленеп чыгуга да тискәре йогынты ясарга мөмкин.

ТИСКӘРЕ ЙОГЫНТЫСЫ БУЛЫРГА МӨМКИН. КУЛЛАНЫР АЛДЫННАН ТАБИБ БЕЛӘН КИҢӘШЕГЕЗ.

Валентина СЕМЕНОВА

КЫЯР КОРЫЙ...

«Әле июль ахыры да җитмәде, кыяр сабаклары инде кибә-корый, саргая башлады». Соңгы араларда бакчачылар арасында шундыйрак сүзләрне еш ишетергә туры килә. Әле бер атна элек кенә ямь-яшел утырган кыярлар ни өчен кинәт кенә ямьсезләнеп, төссезләнеп киткән соң? Белгечләр моның сәбәпләрен һәм аннан котылу юлларын болайрак аңлатмакчы.

vk.com

1 Су дөрес сибелмәгән.

Суны аз сипкәндә дә, артык күп булганда да кыяр үсентеләре шиңә, корый. Түбәндәге киңәшләрне истә тотыгыз.

! Кыяр тутәлләренә еш, әмма бик күп сипмәскә кирәк. Атнасына 2–3 тапкыр, бер төпкә 5–6 литр чамасы су сибелсә, шул җитә.

2 Дөрес тукландырмау.

Үсентеләр тукландыру җитмәсә дә, чамасын белми ашлаганда да корый.

! Иң яхшысы – утыртканда, һәр чокырга ярты чәй кашыгы күләмендә нитроаммофоска салып калдыру. Ә инде чәчәк атканнан соң, шушы ашламаның эремәсен (10 литр суга 2 чәй кашыгы исәбеннән) сибү әйбәт булачак.

3 Сорты шундый.

Үсентеләрнең гомере чикләнгән. Сортына карап, 2,5–5 ай чамасы яши алар. Мәсәлән, «ультраранний» сортлар соң өлгерешлеләренә караганда күпкә тизрәк картая.

! Җәй башыннан кара көзгә кадәр табыныгыздан кыяр өзелмәсен өчен, орлыкларның барысын да берьюлы түгел, ә берничә этапта чәчәргә, төрле вакытларда өлгерә торган үсентеләрне үстерергә кирәк.

4 Корткычлар.

Кыяр өчен иң хәтәре – үлән бете һәм үрмәкүч талпаны.

! Үлән бетеннән котылыйм дисәң, 1,5 л суга 10 мл «Искра Био» препаратын салып болгатыгыз һәм зыян килгән үсентеләргә бөркегез. Шулай эшкәрткәннән соң инде 3–4 көн узуга ук уңышны җыеп булачак.

! Үрмәкүч талпанын юкка чыгару өчен, 1 литр суга 8 мл «Акарин» препаратын салып болгатыгыз. Бөркегәндә, яфракларның аскы өлешенә күбрәк игътибар итегез. Препаратның тәэсирен көчәйту өчен үсентеләргә тәмәке тузанын да бөркергә мөмкин.

5 Кара черек.

Гадәттә нәкъ менә шушы гөмбәчек авыруы (аскохитоз) үсентене корыта. Иң элек сабагында соргылт төстәге сыланып торган таплар пәйда була. Шуннан соң алар, агарып, бөтен сабакка тарала. Үсенте яфракларының кырыйлары шиңеп, коңгырт төскә керә, кыярлары кибә.

! Чирнең беренче билгеләре күренүгә, түтәлне «Браво» фунгициды белән эшкәртегез (инструкциясе буенча). 10–14 көннән соң бу эшне янә кабатларга кирәк. Игътибар! Фунгицид белән эшләгәннән соң 20 көн узгач кына кыяр уңышын җыеп алырга мөмкин булачак.

КЫЯР ЛИМОНАДЫ

Сәвия ГАЛИМУЛЛИНА рецепты

Кирәк: *1 л су (лимонад өчен), 200 мл су (сироп өчен), 100–120 г шикәр комы, 300 г кыяр, 1 лимон, 1 лайм, 2–3 бөтнек сабагы.*

Кыяр, бөтнек, цитрус җимешләрен юабыз. Лимонад өчен суны кайнатып чыгарабыз һәм суытабыз. Лимонның кабыгын чистартабыз. Бөтнек яфракларын өзеп алабыз. Тирән эчле табакка 200 мл су салып, шикәр комы, лимон кабыгы, бөтнек яфракларын өстибез. Кайнап чыккач, тагын 1 минут кайнатабыз. Уттан алып, сиропны 30 минут тотабыз (суытабыз).

Лимонның согын сыгабыз. 200 г кыярны вак тишекле угыч аша чыгарып, согын сыгабыз. Калган кыярларны һәм лаймны боҗралап (юка гына) турыйбыз. Сиропны (иләк аша), лимон, кыяр сокларын кувшинга агызабыз. Лайм, кыяр кисәкләрен һәм бөтнек яфракларын өстибез. Су салып болгатабыз. Кувшинны суыткычка куеп, 1 сәгать тотканнан соң эчәбез.

Киңәш-табыш

Авызыңны белеп ач!

Телефон аша ят номерлардан шалтыратучылар күбәйде. Билгесез номердан гадәттә реклама бирүчеләр яки мошенниклар элемтәгә чыга. Бу очракта нәрсә эшләргә? Үзебезне ничек дөрес тотарга һәм алданмаска?

РОБОТ. Телефон номерын безгә төрле урыннарда калдырырга туры килә. Шуңа ул җиңел генә мошенниклар базасына эләгергә мөмкин. Әле моннан ике еллап элегрәк кенә безгә махсус ялланган кешеләр шалтыратса, хәзер асылда робот тавышын ишетергә туры килә. Кайвакыт чыбыкның теге очында «тимер кеше» иконлеген абайламыйча да каласың. Әгәр аның беренче соравына «дөрес итеп» җавап бирсәң, сөйләшүне инде чын кеше дәвам итәчәк.

Робот сүзен гадәттә «исәнмесез, сезгә кредит хупланды»; «түләү буенча мәгълүматларыгыз үзгәрде»; «сезнең картадан шикле акча күчте» кебегрәк җөмләләрдән башлап җибәрә. Иң мөһиме һәм иң җиңеле – таныш булмаган номерлардан шалтыратканда, телефонны алмау. Дөрес, кайвакыт алырга да туры килә (әйтик, нәрсәгәдер заказ биреп, шуны көткәндә). Сак булыгыз: бернинди дә банк хезмәткәрләре мондый сәбәпләр буенча шалтыратмый. Банктагыларга акча күчерү шикле тоела икән, алар ул картаны яба да, шуның белән шул. Аннан инде картаның нигә эшләмәгәнен үзебезгә ачыклыйсы кала.

ҖАВАП. Беренче җөмләне тыңлап бетергәннән соң, «банк хезмәткәре» соравына ялгыш кына җавап бирү картадагы акчадан коры калуны аңлатмый анысы. Бер генә банк та аны-моны уйламыйча әйтелгән бер сүз аркасында акчагыздан коры калдырмаячак чөнки. Ә ничек җавап бирергә соң? Иң яхшысы – берни дә әйтмичә, телефонны куярга. Кайвакыт хәтта бик акыллы, зирәк кеше дә оста психолог «кармагы»на эләгергә мөмкин. Тиге яки бу сорау белән баш катыра башлыйлар икән, банкка үзең шалтыратып белешүдән дә хәерлесе юк.

КОТЫЛУ. Кирәкмәгән шалтыратучылардан котылуның иң яхшы юлы – телефон номерын беркайда да калдырмау, әлбәттә. Ләкин хәзерге вакытта мөмкин булмастай эш шул бу. Белеп торыгыз: роботларга еш кына кемнәрнеңдер трубканы аламы-юкмы икәнен тикшерү генә йөкләнә. Трубканы алмаган очракта, шалтыратулар кимеячәк. Номер, «эшләми» дип, исемлектән үк төшереп калдырылачак.

Шалтыратулардан башкачарак – җитдирәк ысул белән дә котылырга мөмкин. Android системасында эшләүче күп кенә смартфоннарның спам-шалтыратуларны тоткарлап калучы функциясе бар. Аның кайда икәнлеген табып, эшкә генә җигәсе. Мондый функциясе юк икән, номерны билгеләп, спаммы-түгелме икәнен әйтеп бирүче махсус кушымталар урнаштырырга мөмкин.

Кирәге чыгар

Начар үссә

Кишер начар үссә, түтәлгә тозлы су сибегез. Моның өчен 10 литр суга 1 аш кашыгы тоз исәбеннән эремә ясагыз. Тоз эреп беткәч кенә сибәргә кирәк.

Беләсезме?

КАБЫГЫ КУПМАСА

Кабыгын җиңел генә чистарту өчен, йомырканы кайнар суга салып пешерергә кирәк. Ә инде ярылып китмәсен өчен, кәстрүлгә салганчы, җылымса суда бераз тотарга. Салкын суга салып пешергән очракта, су әкренләп җылыну сәбәпле, аксымы кабыкның эчке өлешенә ябышып кала.

ЙОМЫРКА ТӘБӘСЕ СЕРЕ

Тәбә ниндидер сыекчада йөзеп йөрүче коры, аксыл эремчеккә охшап калмасын өчен, тозны дөрес салырга кирәк. Йомырканы сытып күперткәч, тоз салабыз да 15 минут тотабыз. Шуннан сөт өстәп пешерәбез. Тозны ризыкның пешү барышында түгел, ә баштан ук салган очракта, йомырка тәбәсенең төсе дә үзгәрмәячәк, бик тәмле булып, күпереп пешәчәк.

Аш-су

Ташкабактан – коймак

Гөлфия НУРГАЛИЕВА рецепты

Кирәк: *кечкенә генә 2 ташкабак, 2 йомырка, 4 аш кашыгы манный ярмасы яки он, бер чеметем тоз, үсемлек мае.*

Ташкабакны кабыгы һәм орлыкларыннан чистартып, вак тишекле угычтан уабыз. Согын сыгып алабыз. Йомырка һәм манный ярмасы (он) өстәп болгатабыз. Тоз сибәбез. Майлы табага (бераз кыздырырга кирәк) салып, коймак пешерәбез. Каймак һәм яшел тәмләткечләр (ваклап туралган) белән табынга куябыз.

КҮРШЕ БЕЛӘН КҮРКӘМ ЯШӘҮ – ИМАН БИЛГЕСЕ

ru.freepik.com

Күршеләр – иң якын кешеләр, дип җырлана җырда. Күршеләргә карата яхшы мөнәсәбәттә булу турында динебез дә искәртә. Ничә йортка кадәр күрше санала? Күршеләргә нинди мөнәсәбәттә булырга кирәк?

Әлеге һәм башка сорауларга «Билал» мәчете имамы Җәлил хәзрәт ШӘВӘЛИЕВ ачыклык кертте.

:: «Күрше хакы – Алла хакы», – ди халык. Динебездә күршеләр турында ни диелә? Аларның хакы, чыннан да, зурмы?

– Күршеләргә яхшы мөнәсәбәттә булырга кирәклеген Аллаһы Тәгалә безгә Коръәни Кәримнең «Ән-Ниса» сүрәсенең 36 нчы аятендә: «Аллаһы Тәгаләгә гыйбадәт кылыгыз, аңа тиңне кормәгез, әтиәниләрегезгә, туганнарыгызга, ятимнәргә, фәкыйрьләргә, шулай ук якын яки ерак булган күршеләрегезгә, мосафирларга, әсирләргә яхшы мөнәсәбәттә булыгыз», – ди. Алар арасында, күргәнебезчә, якын һәм ерак күршеләребез дә бар.

:: Күршеләргә нинди мөнәсәбәттә булырга куша динебез?

– Пәйгамбәребез (с.г.в.): «Аллаһның барлыгына, берлегенә инанган кеше күршесе белән яхшы яшәсен», – дигән. Күрше белән яхшы яшәү иманның бер билгесе булып тора. Күршебезнең нинди диндә булуы да мөһим түгел, күрше хакы барлык диндәгеләргә дә кагыла. Син аларның диненә катнашмыйсың, тик, күрше буларак, хакын хакларга тиеш буласың.

Пәйгамбәребезнең (с.г.в.) бер күршесе яһүд була. Бу күрше аның ишек төбенә гел чүп ташлый икән. Пәйгамбәребезнең (с.г.в.) һәр яңа иртәсе чүп җыештырудан башлана. Көннәрдән бер көнне, ишек төбендә чүп күренмәгәч, пәйгамбәребез күршесенә керә.

– Нәрсә булды? Авырып киттеңме әллә? – дип сорый.

Күршесе, чыннан да, авырып ята икән. Шул ук вакытта пәйгамбәребезгә китергән зыянны да аңлый, чүп ташлаганын да белә. Ул инде күршесенең аңа тавыш күтәргәнен көтеп ята икән. Тик пәйгамбәребезнең хәл белергә генә кергәнен аңлагач, күзләре яшьләнә. Шуннан соң хәтта улына да ислам динен кабул итәргә васыять итеп калдыра.

:: Ничә йортка кадәр күрше санала?

– Халкыбыз: «Кырык йортка кадәр – күрше», – ди. Уң һәм сул яктан бу. Шәһәр җирендә, күпкатлы йортта торабыз икән, анда яшәүчеләр бөтенесе дә күрше булып саналачак. Хәтта күрше йорттагылар да – күрше. Авыл җирендә исә бер урамда яшәүчеләрне күршеләр диләр. Әлбәттә, кырык йорт, бер караганда, бик күп булып тоелыр. Ләкин, икенче яктан, синең тормышың шушы кешеләргә бәйле бит. Алар белән еш күрешәсең, аралашасың, бер урамнан йөрисең, дигәндәй. Шуңа күрә, кырык йорт дигән сүздә гаделлек бар.

:: Дин күзлегеннән караганда «идеаль күрше» нинди була?

– Күршең авырса, аның хәлен белергә; үлә икән, җеназасында катнашырга; шатлык килсә, сөенергә; кайгы килсә, көенергә; бурычка акча сорап керсә, бирергә; әштә ярдәм сорап керсә, булышырга; еракка китә икән, гаиләсенә булышырга; Коръән ашына чакырса, керергә. Бу – мөселман өстендәге бурычлар. Шушы хакларга үтәлә икән, димәк, син – иң хәерле күрше.

Гыйбрәт ал!

«Коръән сине үзгәртә»

Тауларда үзенең оныгы белән бер бабай яшәгән, ди. Ул һәр иртәсен Коръән укуга багышлаган. Оныгы, аңа охшарга тырышып, бабасы ни кылса, шуны кабатлап барган. Бервакыт бу бала:

– Бабай, мин Коръән китабын синең кебек укып барырга тырышам, әмма мин аның мәгънәсен аңламыйм. Мин китапны ябу белән, ятлаган әйберләрем башымнан чыга. Шулай булгач, Коръәни Кәрим китабын укудан нинди файда бар соң? – дип сорый икән.

Мичкә ташкүмер сала башлаган бабасы, туктап:

– Бар, улым, ташкүмер кәрзинен ал да, елгага төшеп, су алып мен, – дип йомыш кушкан.

Оныгы шулай эшли дә. Әмма ул тау башына менеп җиткәнче, су кәрзиннән агып беткән була инде. Моны күреп, бабасы елмаеп куя һәм:

– Син тизрәк атлап кара, – дип әйтеп, оныгын кабаттан су алырга төшереп җибәрә.

Монысында инде малай тизрәк атларга тырыша. Әмма файдасыз. Бабасы моны күреп: «Әмма миңа бер кәрзин су кирәк. Син бар көченне куеп эшләргә тиешсең генә», – ди.

Оныгы, бу хәлнең мөмкин түгеллеген исбатлар өчен, кабаттан елга буена төшеп китә. Ул кәрзиненә су тутырып ала да бар көченә бабасы янына чаба башлый. Әмма менеп җиткәнче, су агып беткән була. Хәленнән тайган малай: «Менә, бабай, әйттем бит мин сиңа – болай булмый», – дип куя.

– Син моны мәгънәсез дип уйлыйсыңмы? – дип сорый бабасы шулчак. – Кәрзингә кара әле!

Оныгы кәрзингә караса, ташкүмердән каралып беткән кәрзин эчтән дә, тышкы яктан да чистарган икән! «Балам, Коръән укыган вакытта менә ниләр була. Син аны укыган вакытта аңламаска да, истә дә калдырмаска мөмкинсең. Әмма ул сине эчке яктан да, тышкы яктан да үзгәртергә сәләтле. Менә шул рәвешле Аллаһы Тәгалә безнең тормышыбызны да үзгәртә».

Йөгез, бер дога!

КУРКЫНЫЧ ТӨШ КҮРГӘЧ УКЫЛА

«Әгүүзү бикәлимәәтиллләәһиттәәәммәәти мин гадабиһи үә гикаабиһи үә шәрри гибәәдиһи үә мин һәмәзәәтиш-шәйәәтыыйни үә әй йәхдурууун».

Мәгънәсе: «Аллаһым, бөтен сүзләр белән Аның ачуыннан, колларының начарлыгыннан, шайтанның котыртуыннан һәм аларның каршысында булуыннан Аллаһыга сыенам».

Белеп тор!

КОРЪӘН УКУ ӘДӘПЛӘРЕ

✓Һәрвакыт тәкъва, җитди һәм тыйнак булырга.
✓Буш һәм мәгънәсез, начар мәгънәле сүзләр сөйләүдән читләшергә.
✓Оялчан булырга.
✓Күзләр һәрвакыт кайгылы күз яшьләре белән тулган булырга тиеш.

АЗАН ӘЙТҮ ӘДӘПЛӘРЕ

✓Мәзин намаз вакыты керү-кермәү мәсьәләләренә үтә дә игътибарлы булырга тиеш.
✓Азан әйтелгән вакытта як-якка карамаска.
✓Азан вакытында «саләх» һәм «фәләх» кәлимәләрен әйткәндә, башны уң һәм сул тарафларга борырга.
✓Азанны ашыкмыйча, ачык итеп, ә камәтне тизрәк әйтергә.

(Имам Әбү Хәмид Әл-Газалинең «Әдәпләр» китабыннан алынды)



Хикмәтле сүз

«Без, һичшиксез, сезне бераз – курку белән, бераз – ачлык белән һәм маллагызга, җаннарыгызга, [бакча-басулагызга афәтләр җибәреп] уңышларыгызга бераз зыян китерү белән сыныйбыз. [Расүлем!] [Сынауларга] Сабыр итүчеләрне [җәннәт белән] сөендер! Берәр бәлагә юлыкканнар: «Һичшиксез, без – Аллаһыныкылар һәм Аңа гына кайтачакбыз!» – дип әйтәләр. Әнә шулар – Раббыларының мәгъфирәтенә һәм рәхмәтенә ирешүчеләр, һәм әнә шулар – [башларына төшкән бәлаләргә сабыр итеп, туры юлга] һидаять табучылар».

«Әл-Бәкара/Сыер», 2:155–157

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА әзерләде

Мин = милләт

Асыл

ДЕНИС ДЕНИСОВ, РУС, 41 ЯШЬ

Көндәлек тормышта милли асылымны **ИҖАТ АША** чагылдырам дип уйлыйм. Эшемә дә эш итеп кенә карамыйм чөнки. Җыр, музыка, рус фольклоры… Бу инде – минем **ТОРМЫШЫМ, МИН АНЫҢ ЭЧЕНДӘ КАЙНЫЙМ**. Шул очракта гына **МӘГЪНӘГӘ, АСЫЛГА ТӨШЕНӘСЕҢ**. Бик күп әйберләрне аңлыйсың. Концертка килдең дә, нидер җырладың да, аннан соң инде башка тормыш белән яшәү дөрес түгел, минемчә. Мин, милли чараларның эчендә кайнаган кеше буларак, моны булдыра да алмыйм.

ЧИТТӘН КЕРГӘН СҮЗЛӘРДӘН КОТЫЛЫП БУЛМЫЙ, ӘММА АНА ТЕЛЕНДӘ СӨЙЛӘШКӘНДӘ АЛАРДАН ФАЙДАЛАНМАСАК ИДЕ. Әнә шул борчый. Әйтик, мин хәзер «окей» сүзен кулланмыйм. Аның урынына күпме үз сүзебез бар бит! Әйе, «окей» дип язу тизрәк тә, җиңелрәктер дә. **ӘММА ВАКЫТ ЯГЫН КАЙГЫРТАМ ДИП, ТЕЛДӘН ВАЗ КИЧӘСЕ КИЛМИ.**

Гаиләдә, әлбәттә, **ТРАДИЦИЯЛӘР САКЛАНА**. Бездә моңа җитди карыйлар. Мин – авылда үскән егет. Традицияләрне сендергән өчен, аларның үтәлешен үз күзләрем белән күрү мөмкинлеген биргән өчен, әти-әниемә, туганнарыма рәхмәтлемен. **БӘЙРӘМНӘР БУЛСА ДА, БЕР СӘБӘПСЕЗ ҖЫЕЛЫШСАК ТА, МУЗЫКА УЕН КОРАЛЛАРЫНДА УЙНЫЙ, ҖЫРЛЫЙ ИДЕК**. Сүз уңаеннан, җырга-моңга мәхәббәт нәселебездән килә. Хәзер үз гаиләмдә дә гореф-гадәтләргә җитди караш тәрбияләргә тырышам.

Җырларыбызда элекке чор чагылышын сакларга тырышабыз. Өйрәнгәндә авыррак булса да, андый **МИРАСКА САК КАГЫЛЫРГА КИРӘК**. Артык заманчалаштыру кирәкми.

УЛЫМА – 6 ЯШЬ. УЛ ДА БЕЗНЕҢ БЕЛӘН ҖЫРЛЫЙ. Иҗат аша ул да телне, традицияләрне саклап калуның ни икәнен аңлый.

Җыр кешене гомере буе озата бара. Хезмәттә, бәйрәмдә, көнкүрештә. **ХАЛЫК ИҖАТЫНДАГЫ КЕБЕК ҮК, ҖЫРДА ДА АНЫҢ ЯШӘЕШЕ, БАТЫРЛЫГЫ, ТУГАН ЯГЫНЫҢ ГҮЗӘЛЛЕГЕ, МАТУР СЫЙФАТЛАРГА ОМТЫЛЫШЫ ЧАГЫЛЫШ ТАПКАН. ҖЫР ӘХЛАКНЫ БУЛДЫРУДА ХЕЗМӘТ ИТӘ.**

ТӨРЛЕ АВЫЛЛАРГА ЭКСПЕДИЦИЯЛӘР БЕЛӘН ЙӨРГӘНДӘ, ТЕЛНЕҢ, МӘДӘНИЯТНЕҢ БАЙЛЫГЫНА СОКЛАНЫП КАЙТАМ. ҺӘР ҖИРНЕҢ – ҮЗ СӨЙЛӘМЕ, ҮЗЕНЧӘЛЕКЛЕ ТЕЛЕ. Аларны тыңлау үзе бер рәхәт.

Денис Казахстанда туган. 1999 елда аларның гаиләсе Удмуртиягә күчеп килә. Денис шунда мәдәният училищесын тәмамлый. Аннан исә Татарстанда белем ала. Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать университетында укытырга да өлгерә, Дәүләт камера хорында эшләп ала. 2019 елдан исә Пушкин исемендәге үзәктә эшли башлый, фольклор коллективын җитәкли.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА әзерләде. Фото: Анна АРАХАМИЯ

26 июль | Чәршәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълумати-күңел ачу программасы 16+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «БЕР-БЕР ХӘЛ». Телевизион нәфис фильм 16+
«Бәрле елгасы буенда авыллар бер-бер артлы сәйлән кебек тезелеп утырган, Морзаныкы бер урамлы гына, урман эчендә урнашкан», – дип аңлатып җибәргәннәр иде югыйсә. Әмма без борылыштан соң, ялгышып, Бәрлебаш авылының руслар яши торган ягына килеп чыкканбыз. Аның да бер урамы диярлек кенә калган, бөтен тирә-юнен агач каплаган, урманнан бер дә ким түгел. Тик йортлары гына бик тузган, ташландыклары да күп. «Бер дә татар авылына охшамаган бу», – дия-дия, урам очына чыгып җиттек. Умарталар да күренми. Кайда йөргәнлекне белергә теләп, бер капкага төртеләм, икенчесенә... Бикле. Берсенә шакый торгач, ниһаять, бер апа пәйда булды. Татарча исәнләшүебезгә русча җавап ишеткәч кенә аңлап алдык. Бөтен җир бикле, кеше яшәми, ахры, сездә, дигәнгә: «Безнең авылда эт тә юк», – дип җавап кайтарды. Безнең авыл дигәне бик туры килеп бетми инде, әлбәттә. Бәрлебашның татарлар яши торган өлеше гөрләп утыра (элек ул ике авыл булып, Рус Бәрлебашы һәм Татар Бәрлебашы дип аталган икән). Татар өлешендә бик тырыш, эшчән халык гомер иткәнлеге күренеп тора. Рус ягында яшәүчеләр, күрәсең, күченеп китүне җайлырак тапканнар. Мондый хәл, бәлки, тарихка да бәйледер. Руслар – төрле чорларда күчереп утыртылган халык, ә татарлар өчен бу – әби-бабайлар яшәгән изге җир.

Без эзләгән авыл тагын ике чакрым арырак, чыннан да, урман эчендә булып чыкты. Кайбыч район үзәгендәге мәктәп директоры Исламия ханым Мусина шунда яши дигәч, аның телефон номерын алган идек. Борылышта чагында ук шалтыраткач, каршы алам, хәзер чыгам, дигән иде. Бәрлебашта йөри-йөри шактый вакыт үтеп китте бит инде. Көткән-көткәндер дә кереп киткәндер. Бер урамлы авылның икенче башына чыгып җитә язганда, ниһаять, капка төбендә бал кортларыннан саклану өчен битлек кигән бер кеше очрады. «Мин бу авылны белмим шул. Бал кортлары карарга гына киләм», – дигәч, артка борылып караган идек. Авылның без кергән башында бер хатын-кыз кул болгап тора. Исламия ханымдыр инде, диештек. Ул арада ачык калган ишектән машинабыз эченә бал кортлары кереп тулган булып чыкты. Дөрес юлда йөргәнебезгә чынлап торып ышандык.

Бер урамлы авылның рәхәт яклары да бар икән үзе. Бер башына чыксаң, икенчесен күрергә була. Ә яшәр өчен... Бакча артында елга, уйсу җирләр, аннан урман башлана. Беркем беркемгә комачауламый. Чагыштырмача яңа авыл икән әле бу Морза Бәрлебашы.

> Тарих битләреннән күренгәнчә, XX гасыр башында крестьяннар җиргә кытлык кичерә башлый. Авыл кешесе, гаиләсен туендыру өчен, кәсепчелек белән шөгыльләнергә мәҗбүр була. Шушы хәлләрнең нәтиҗәсе буларак, 1929–1930 елларда халыкның бер өлеше Морза Бәрлебашы авылына нигез сала. Төп кәсепләре бүгенгә кадәр дәвам иткән, үзләре әйтмешли, «марта» асрыйлар. Бу авылга заманында күчле, хәлле, ягъни морзалар нәселеннән булган кешеләр күчеп утыра.

Әни теләгәнчә...

– Тәүзәр, кунаклар килде. Синнән әйбәтрәк таныштыручы булмас, – дип сөрән салгач, бакча ягыннан бер күч бал кортлары ияртеп: «Менә без шулай «марта» асрыйбыз инде», – дия-дия йорт хуҗасы килеп чыкты. Өйгә кереп качудан башка чара калмады.

– Сезнең авылда бөтен кеше умарта асрый, дигәннәр иде. Чынлап та, дөресме ул? – дип кызыксынам.

– Барысында да юк инде. Олыгаеп китеп, бик эшли алмаучылар бу шөгыльне ташларга мәҗбүр. Менә безнең күрше әби ялгызы калгач та бик озак еллар асрады әле. Хәзер авыраеп китте инде, – диештеләр хуҗалар.

– Бу кәсеп бик файдалыдыр инде? – дип дәвам итәм сүземне.

– Элегрәк, чыннан да, бик әйбәт булды. Сезон башлангач, һәр гаилә, быел машина алам, яисә, өй салам, тагын берәр нәрсә эшлим, дип планлаштырып куйды. Һәм теләгенә ирешә дә иде. Хәзер алай ук түгел инде. Бал корты үрчетү белән шөгыльләнүчеләр күп бит. Шуңа күрә сату мәсьәләсендә проблема килеп туа. Әмма ничек кенә булмасын, без бу эштән туктый алмыйбыз. Әби-бабайлардан килгән шөгыль бит. Мирас кебегрәк ул безнең авылда. Дөрес, әтиебез гомере буе урманчылыкта мастер булып эшләде. Арбасын да, чанасын да, көрәген дә ясады. Умарталарны әниебез карады. Без аңа булышып үстек, – ди Тәүзәр.

Мусиннар гаиләсендә өч ир-бала үсә. Олысы Айдар белән кечесе Ирек медицина институтын тәмамлыйлар, берсе – Олы Кайбычта, икенчесе – Казанда теш табибы. Ә Тәүзәр Казан педагогия институтының физмат бүлеген тәмамлый да менә инде 32 ел үзе укыган Бәрлебаш мәктәбендә укыта. Укытучылар җитмәгәнлектән, Кайбыч мәктәбендә дә белем бирә. Үзе, әллә уйнап, әллә уйлап шунда, аптыраган була: «Әтинең мине төп нигездә калдырасы килгән, ахры. Кечкенә чагымда ук, улым, син укытучы буларсың, диде. Минем дә табиблыкка китәргә теләгем бар иде: әти сүзеннән чыкмадым. Үзем дә гаҗәпләнәм: йорт хуҗасы булып кечкенә бала калырга тиеш иде ул. Ничектер, бу хакта сүз дә булмады кебек. Өйләнүен дә беренче булып мин өйләндем», – ди. «Әтиең, син тугач ук, шулай тиеш дип тапкандыр. Исемеңне дә үзенә охшатып куйган бит», – дим. Үземчә шаяртам инде. Әтисе Тәүзих исемле аның. Моннан алты ел элек дөнья куйган. Әнисе Гөлфирә апа бик сагынып яши. 59 ел бергә яшәдек, дигән сүзләрне бик еш кабатлый. Әле ярый балаларым әйбәт булды, дигән сүзләрне дә калдырмый.

– Бер елны Казанда хастаханәдә яткан идем. Бер-бер артлы әле улларым, әле оныкларым килеп торды. Малайларны ничек шулай яхшы тәрбияли алдың дип, палатада ятучылар шаккаттылар. Кызлар эшенә дә куллары бик ятты: өйне дә юдылар, киләксә, ашарга да пешерделәр. Киленнәрем дә үз кызларым кебек, шөкер. Өчесеннән дә бик уңдым, – дип мактанып та алды.

Хәер, мактанырлыгы да бар шул. Күренеп тора: хөрмәткә тиенеп яши Гөлфирә апа бу йортта.

– Сез, бер дә заманча яшәмиләр икән болар, дип уйлый күрмәгез инде. Без әни теләгәнчә яшибез, – ди Исламия дә, күпертеп куелган, чигүле мендәр тышлары киертелгән мендәрләргә ымлап. – Әле өйне юып кына чыккан идем. Улыбыз Булат кайткач, әни стеналарга да элеп куя чигүләрен. Гомер буе чигү чиккән, бик яраткан ул кул эшләрен. Бер дә аерыласы, сандык төбенә җыеп куясы килми. Әниебез бу йортта каенана белән 36 ел яшәгән. Аннан, авырып киткәч, үз әнисен дә алып килгәннәр. Ул 10 ел торган. Улыбыз Булат белән кызыбыз Фирүзә әнә шулай әбиләр белән үсте. Буыннар бәйләнеше өзелмәде.

«Авылча яшисе килә...»

Сөйләшеп утырган арада Исламия ханым өстәлне сый-нигъмәт белән тутырды. Барысы да үзләренеке: сөт, каймак, катык, кортлы тура, эремчек...

– Сыер асрыйбыз, өч бозавыбыз бар. Сөтне сатканыбыз юк. Әнә шулай ризыкларны балаларга да әзерләп куябыз. Күршеләргә, бигрәк тә ялгыз әбиләргә кертәм. Иллегә якын хуҗалык яшәсә дә, авылда 6 гаилә генә сыер асрый. Шуның өчесе – укытучылар. Элек киресенчә булган ул. Укытучыларга эре терлек асрарга рөхсәт тә ителмәгән. Хәзер һәр яктан үрнәк күрсәтмәкче булабыз инде, – ди Исламия шаяру катыш. – Икебез дә эшләп торгач, асрамасак та була инде. Тик авылда барыбер авылча яшисе килә шул...

Шул җәһәттән фәлсәфә корып, озак утырдык әле без Тәүзих абый юкә бурадан салып калдырган ак йортта. Идәннәре дә буяу күрмәгән аның. Яктылык сирпелеп тора. Сулар һава бәлзәм кебек. Яшәр өчен уңайлыклар да бар. Авылы да күркәм. Мәдәният йорты эшләп тора. Бәйрәмнәрдә бергә җыелабыз, диләр. Авылга асфальт килгән. Урамга таш юл җәелгән. Тик авыл барыбер бушый. Элек башлангыч мәктәбе дә булган морзалар авылының. Тәүзәр үзе дә шунда укыган әле. Балалар саны кимегәнлектән, унлап бала хәзер Бәрлебаш авылына йөри.

Кызык бит: заманасына күрә Тәүзих абыйның башы эшләгән. Бер улына авылда көн күрерлек һөнәр биргән. Хәзер инде андый юлга да барып булмый кебек. Булат та, Фирүзә дә абыйлары юлыннан киткән: медицина юлын сайлаган.

«Юлсызлыктан интеккән чакларда үзебезнең дә Кайбычка күченеп китәргә теләгән чаклар күп булды. Хәтта йорт та төзи башлаган идек», – диләр Тәүзәр белән Исламия. Әмма ата-ана хакын хаклап, яшьләр төп нигездә калганнар.

Авылны нинди киләчәк көтә? Бергәләп шул сорауга җавап бирергә тырыштык без. Бу җәһәттән алар район башлыгы, үзе дә Бәрлебаш авылы егете Альберт Рәхмәтуллинга чиксез рәхмәтле.

– Районыбызга яңа сулыш өрде. Барлык авылларда да газ яна, юллар эшләнде, халык суга интекми. Авылга заманча техникага корылган су җайланмасы куелды. Теләгән кешегә Бәрлебаш авылында ферма эшли. Ерак түгел бит. Янәшәдә генә. Кайбычның үзенә дә 7 чакрым гына. Мәктәп, мәдәният йорты, мәчетләрнең буш торганы юк. Башлыгыбыз беркемне дә урап узмый. Бәрле буенда бездән ерак түгел дүрт хуҗалык кына калган авыл бар. Иренеп тормый. Еш кына шунда төшеп, хәлләрен белешеп кайта. Юл буенда калган «Салкын чишмә»не дә күргәнсездер. Яныннан туктамый үтеп китеп булмый...

Киләчәкнең матур буласына ышанып яшиләр Бәрле буенда. Шуңа күрә без дә авылларның бераз гына тезгенне ычкындырып җибәрүләрен вакытлыча күренешкә юрадык. Хәер, эшчән булулары белән дан тоткан нечкә билле бал кортлары янында болай да кул кушырып утырып булмый инде. Әби-бабайлар белеп калдырганнар мирасны.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

ГӨЛЗАДА ШӘРӘФИЕВА:

«ТОРМЫШНЫ ЯРАТСАҢ, УЛ ДА СИҢА ЕЛМАЯ»

Балтач

Балтач районының Яңгул авылында яшәүче халык синоптигы Әмир Шәрәфиев турында ишетмәгән кеше сирәктер. Һава торышын сорашыр өчен, гел аңа шалтыратабыз. Телефонны бик ягымлы ханым ала. Ничә еллар буе хәбәрләшеп торгач, тавышны да таный. Гөлзада апа ул, Әмир абыйның хатыны. Бу юлы Шәрәфиевләрнең өйдәге «һава торышы»н сораштык.

– Без – гап-гади укытучылар инде, сеңлем, – ди Гөлзада апа. – Әмир абыегыз белән бергә яши башлавыбызга 1 августта 48 ел була. Шул вакыт эчендә ике ул үстердек, бер дигән киленнәребез, 5 оныгыбыз бар. Әле генә яши башлаган кебек. Гомер дигәнең туктап тормый. Сизелми үтә дә китә икән.

Укытучылар гаиләсе элек-электән үрнәк саналды. Балаларга белем биргән, аларны язарга-укырга өйрәткән укытучыларга рәхмәт дими ни диярсең. Әмир абый мәктәптә – 40 ел, ә Гөлзада апа 35 ел эшләгән. Мактаулы исемнәр алмасалар да Шәрәфиевләр үз укучыларыннан җылы сүзләрне еш ишетә. Алар Татарстанның Баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыевка да белем биргән. Әле дә очраган саен укытучыларына изге теләкләрен җиткерә икән.

Әмир абый Арча районының Пошалым авылында туып-үскән. Алар гаиләдә ике бала була. Апасы инде исән түгел. Әнисе 90 яшендә вафат булган. Пошалымда әнисенең 96 яшьлек сеңлесе гомер кичерә икән. Әмир абый туганын ташламый, без шалтыратканда, шунда хәл белергә киткән иде.

– Әмир абыегызны Балтач районының Бөрбаш авылына тарих дәресләрен укытырга дип кайтаралар. Ике елдан мине дә, кияүгә чыккан апам Гөлнур урынына, ул чактагы директор Габделхак абый Исхаков РОНОдан үзе соратып кайтарды. Башта курыктым да әле. Апам кебек булдыра алмам, дидем. Юкка борчылганмын икән. Андагы хезмәттәшләремне, ул елларны бик сагынып искә алабыз. Бөрбашта эшләгәндә гаилә кордык, ике улыбыз туды. Авыл халкы белән тату яшәдек. Бер генә чарадан да читтә калмадык, – ди Гөлзада апа.

Шәрәфиевләрне гел каядыр күчереп йөрткәләр. 1979 елда Әмир абыйны Арча районының Лесхоз мәктәбенә директор итеп билгелиләр. Анда биш ел эшлиләр. Шуннан соң Балтач районы хакимияте аларны Яңгул авылына чакырып кайтара. Мәктәпкә тарих һәм география укытучылары кирәк була. Гаилә шунда кайтып төпләнә.

– Яңгулга килеп урнашканчы, алты җирдә яшәдек. Бүгенге нигез җиденчесе. Шөкер, биредә рәхәт яшәргә насыйп булды, – ди Гөлзада апа. – Әмир оста итеп гармунда уйнады, җырлады да әле ул. Туйлар да алып барды. Элек бит гармунчы бик кадерле иде. Иремне мәҗлесләргә, кичәләргә чакыруларын ярата идем. Үзе каршы килсә дә, җаен табып җибәрә идем. Гомерем буе Әмирнең җырга-моңга булган сәләтен кешегә күрсәтәсем килде. Минем өчен иң матур уйнаучы гармунчы ул, иң матуры җырлаучы да – Әмирем. Ә ул киреләнгән була. Янәсе, инде картайган, тавышы матур түгел. Юкка әйтә, бик талантлы ул.

Гөлзада апа ирен мактаган арада, Әмир абый да кайтып керде.

Талант дигәннән, без Әмир абыйның оста синоптик икәнен дә беләбез. Хәзерге заманда һава торышының көен бик белеп бетереп булмый. Әмма Әмир абый язып барганнар, ул фаразлаганнар еш кына тәңгәл килеп куя. Үзе дә яшерми, хәзер алдан әйткәннең туры килмәгән чаклары да бар.

– Төрлечә була. Кайчак, дөрес әйтмәдең, дип тә шалтыраталар. Мин бит галим түгел. Бернинди җиһазларым да юк. Бары тик 1978 елдан бирле бер көн дә калдырмый язып барган көндәлекләрем генә бар. Без укыта башлаган елларда укучылар белән күзәтү көндәлекләре алып бара идек бит. Балалар белән эшләп, үзем дә кызыксынып киттем, – ди ул.

Тышта буран булса булсын, өйдә буран булмасын, дип җырлыйлар бит әле. Гөлзада ападан бәхетле яшәү серләрен дә сораштык.

– Иң беренче бер-береңне аңлап яшәү кирәк. Яшермим, мин Әмирне яратып яшим. Гомумән, күңелемдә начарлык юк. Бар кешене яратам, аларга яхшы булырга телим. Ике улымның тормышына сөенеп яшим. Өйләнүгә, аларны башка чыгарырга кирәк, дидем. Бар теләгем – һәр гаилә үзенчә яшәсен. Икесе дә Казанга якын бистәләрдә, Питрәч районында торалар, – ди Гөлзада апа. – Киленнәрем Алсу белән Гөлназ әни дип өзелеп торалар. Бер дә сүзгә килгәнебез юк. Алар миңа яхшы, мин аларны яратам.

Гөлзада апа – дин юлында. Әмир абый да – мәчет карты инде. Йорт тирәсендә дә эшләре бүленгән. Гөлзада апа бакча эшен бик ярата икән. Күп итеп чәчәкләр үстерә. Әмир абый әле сыер асрый.

– Баштарак икешәр баш та тоттык. Кирәкми, дигән идем. Әмир абыегыз ул сүзне яратмый. Сыерны үзе сава, үзе карый. Мин дә булышкалыйм инде. Бер-беребезгә юл куеп яшәдек. Әле дә шулай. Телевизорны бергә карыйбыз, бер төрле уйлыйбыз. Икебез бербөтен булдык инде. Туган көннәребез дә бер безнең: 1951 елның 22 гыйнварында туганбыз, – ди Гөлзада апа. – Язмышлар да уртак булды. Бик рәхәт яшәдек. Әле тагын да матур итеп гомер итсәк иде. Мин тормыштан бик канәгать. Артык малга кызыкмыйм, булганына шөкер, дим. Тормышны яратып яшәсәң, ул да сиңа елмая!

Кайсыгызның кулы җылы?

ВАКЫТЫНДА ӨЛГЕРӘСЕ ИДЕ...



«Ватаным Татарстан» газетасының укучылары ярдәм сораган авыруларны, мохтаҗларны игътибарсыз калдырмый. Пенсия акчасын җыеп барып, башкаларга ярдәм итәр идем дип, редакциягә килүчеләр дә шактый. Үзләре хакында язгач, тормышлары уңайланып китүчеләр, тиешле дәвалану курслары үтүчеләр бар. Алар газетага да, укучыларга да рәхмәтле. Үзебез дә араны өзмибез, хәбәрләшеп яшибез.

Казанда яшәүче Айзирә Зиннәтуллинаның улы 5 яшьлек Риназга ярдәм кирәклеге хакында бер язган идек инде. Сабый кабат мәрхәмәтле кешеләр ярдәменә мохтаҗ. Айзирә өченче баласы белән декретта утыра. Иренең генә акчасын җиткерә алмыйлар.

– Улыбыз тугач, табиблар аны сау-сәламәт диде. Тик 8 ай тулганда, ул авырып китте. Тикшерелә башлагач, әллә нинди авырулары барлыгы ачыкланды. Риназның бер колагы начар ишетә, авыр сөйләшә, аяклары тыңлап бетермәгәч, начар йөри, – ди әнисе.

Риназ белән йөкле чакта Айзирә кибеттә эшләгән. Авыр да күтәрергә туры килгән, бер тапкыр сабыен югалта да язган. Хастаханәдә ятып чыккач, хәле яхшырган.

– Баламны тагын да кечкенәрәк чакта дәвалый башлыйсы калган икән, дим. Мин аның утырмавына, үрмәли алмавына игътибар иттем. Табибларга бардым. Алар исә бер дә начар сүз әйтмәде, борчылмаска кушты. Табибларга йөшап тынычландым. Тик улымның хәле тагын да начарланды. Бу юлы тикшерелгәч инде ДЦПның бер төрен ачыкладылар. Риназның нерв системасына зыян килгән. Берни әйтеп аңлата алмый, – ди Айзирә.

Айзирә Риназның ишетмәвенә дә бик борчыла. Күпме генә табибларга йөрсәләр дә, берәү дә әлегә кадәр төгәл диагноз куймаган. Шуңа колак аппараты да алмаганнар. Сабыйның аяклары да борчый, табаннарында кимчелекләр күп. Әкренләп алар кәкрәеп бара икән. Август ахырында аякларына операция ясатырга җыеналар.

– Быел олы балам укырга керә. Ул мәктәпкә барганчы, Риназга операция ясатырга җыенабыз. Бушлай ясала торганын озак көтәсе бар. Түләүлесе тизрәк була. Безгә вакытында баламның аякларын саклап калырга кирәк, – ди Айзирә. – Моңа кадәр туганнарым булышты. Инде алардан ярдәм сорарга да уңайсыз. Сез газетага язганнан соң, безгә бик күп кеше ярдәм итте. Ул чакта күпме анализлар тапшыра алдык. ЛФК үттек. Бар өметем – мәрхәмәтле кешеләрдә. Мөмкинлегем булса, кешедән акча да сорамас идем. Тик булмый... Улымны яшәтәсем килә, аның ныклап йөрүен телим. Калган авыруларын ничек тә җиңәр идек әле.

Риназга булышырга теләүчеләр банк картасына акча сала ала. Саклык банкы картасы әнисе Айзирә Айдар кызы Зиннәтуллинаның **89655965191** телефон номерына беркетелгән.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

НӘҖИП НӘККАШ:

«ТУГРА УЛ – ШӘХЕСНЕҢ БИЛГЕСЕ»

Туксанынчы елларда каллиграфия сәнгатен кабат кулланышка кертеп җибәргән рәссам, каллиграф-хаттат Нәҗип НӘККАШ белән очрашкан саен, милли мәгариф, татар язулары, Казан каласының милли бизәлеше турында сөйләшәбез. Кызганыч, кайбер мәсьәләләр элек ничек булса, хәзер дә хәл ителмәгән, кайберләрендә артка чигенү дә бар. Ярый әле шулар янәшәсендә яхшы яңалыклар да очрый. Нәҗип абый шундый инде ул: көендерә дә, сөендерә дә белә. Бу әңгәмә – әнә шулар һәм каллиграфия сәнгатенең көче хакында.

:: Нәҗип абый, каллиграфия сәнгате Татарстанга бүген ни дәрәҗәдә якын?

– Гарәп язуы безгә элеккеге традицияләрне дәвам иттерер һәм тарихтан өзелмәс өчен кирәк. Аның 1100 еллык тарихы бар. Ул Идел буе Болгарында ислам динен кабул итүгә бәйле. Билгеле бер чорда без әлеге хәзинәдән өзелеп тордык. Узган гасырның 90 нчы елларындагы үзгәрешләр исә мирасыбызга әйләнеп кайтырга юл ачты. Элек тыелган язмаларны да чыгарырга мөмкинлек туды. Нәтиҗәдә гарәп язуы сәнгати дәрәҗәдә югары булган вакытлардагы кебек үк, мәйданга чыга башлады. Мин менә шул дулкында каллиграфия иҗатына килдем. 90 нчы еллар башында Коръән аятьләрен, хәдисләрне популярлаштыру максатыннан, сәнгати дәрәҗәдә бизәп яза башладым. Ул елларда яңа басмалар барлыкка килде. Аның берсендә – «Мирас» журналында – дини һәм борынгы әдәбиятка урын бирелде. Мин аның беренче санынннан ук тышлыкның арткы ягына шәмаилләр яза башладым. Беренче шәмаил «Сөембикә айлы булды» дип аталды. 1991 елның сентябрендә Сөембикә манарасына ай куелды, менә шул вакыйганы чагылдырасым килде. «Мирас» журналына кадәр «Ватаным Татарстан» газетасы өчен дә аклы-каралы шәмаил эшләгән идем. Анда Сөембикә манарасы сурәтләнде һәм Тукайның «Пар ат» шигыреннән «Мондадыр безнең бабайлар түрләре-почмаклары;/ Мондадыр дәртле күңелнең хурлары, ожмахлары…/ И Казан! Дәртле Казан! Нурлы Казан! Моңлы Казан!» дигән юлларын яздым. Үзәккә Коръәннән «Хаклык килде, ялган юкка чыкты» дигән мәгънәдәге аять урнаштырдым. Шәмаил язу менә шуннан башланып китте. Татарча, гарәпчә текстларны берләштерү аларның үзенчәлегенә әйләнде. «Мирас» журналында бу эш 1996 елга кадәр дәвам итте. Акрынлап башка басмалар да, календарь чыгаручылар да заказ бирә башлады. Әйтик, Фәния Хуҗахмәт чыгарган «Татар мөселман календаре»ның беренче санынннан ук тышлыгы бизәлешенә минем кул керде. Шулай ук һәр календарьның арткы тышлыгын шәмаил белән бизәдек. Быел әлеге календарьның утызынчысы чыкты. Ул инде брендка әйләнде. Мөгаен, шәмаилләрнең яктылыгы да моңа тәэсир итмичә калмагандыр.

Каллиграфия сәнгате бүген мәчетләр бизәлешендә актив кулланыла. Аның беренче үрнәге дип Түбән Кама шәһәрендәге җәмигъ мәчетне әйтергә буладыр. Аның бизәлешендә минем эскизлар буенча эшләнгән мозаика кулланылды. Әлеге мәчетне дизайнер-архитекторлар – ирле-хатынлы Мусиннар эшләде. Алар белән хезмәттәшлек әле дә дәвам итә. Нәтиҗәдә Шаңгалче мәчете (архитекторы – Айвар Саттаров), Лениногорск җәмигъ мәчете, Башкортстандагы Кантюковка авылындагы Аллаһ йорты каллиграфия мозаикасы белән бизәлде. Казанда «Ярдәм», Габдерәхим Утыз-Имәни исемендәге һәм башка мәчетләр бизәлешендә куфи шрифтын кулландык. Мозаика өчен ул бик кулай. Гарәби каллиграфия мөселман кабер ташларында да кулланыла. Монда мин Казан ханлыгы традицияләрендәге бизәлешне тәкъдим итәм. Аның үзенчәлеге – Коръән аятеннән тыш, дога һәм теләк рәвешендә «Аңа Аллаһы Тәгаләнең киң рәхмәтләре булсын» дигән язу, әскә шәхеснең туграсын урнаштыру. Шундый үрнәктә халык җырчысы Рафаэль Ильясовның кабер ташы эскизын ясадым. Әлеге эскиз җырчы һәм аның хатыны каберләрен тоташтыра. Җыеп әйткәндә, каллиграфия, артык популярлашып китмәсә дә, тормышта кулланыла.

> Хәзер сәнгатьнең әлеге төре белән кызыксынучыларга күпкә җиңелрәк, чөнки Россия Ислам университетында профессиональ дәрәҗәдә укыту бар. Әйтергә кирәк, җиңел юнәлеш түгел. Университет мөгаллиме Рамил Насыйбуллов әйтүенчә, уку елы башында берничә дистә кеше булса, ахырга кадәр берничә кеше генә барып җитә. Рамил – бик талантлы, төгәл һәм таләпчән кеше.

:: Рус милләтеннән булган рәссам, Тукай премиясе лауреаты Владимир Попов та, яше җитмештән узгач, иҗатта юнәлешен 180 градуска үзгәртеп, каллиграфия юнәлешенә кереп китте. Моның сере нәрсәдә?

– Чыннан да Владимир Поповны без элек күбрәк социалистик реализм рухында иҗат итүче рәссам буларак белә идек. Соңыннан исә ул юнәлешен, тормышка карашын да үзгәртте. Моның сәбәбе – рухи кризис та, икътисадый кризис та. Ник дигәндә, билгеле бер чорда идеологиягә буйсынган картиналарга гына түгел, хәтта пейзажларга да сорау кимеде. Рәссамнар бик авыр хәлдә калды. Советлар вакытында өстән заказлар бирелсә, туксанынчы елларда дәүләт заказлары бетте диярлек. Мондый шартларда иҗат мәйданында калу өчен шактый тырышырга, эзләнергә кирәк, билгеле. Шунда аның кулына типографик шәмаилләрнең аталы коллекциясе килеп керә… Әлеге коллекцияне галим, рухани Иван Покровский туплаган. Инде картаеп, авырый башлагач, 1941 елда ул әлеге коллекцияне Милли музейга бүләк итеп калдыра. Баксаң, коллекция 70 шамаилдән төр тормаган икән. Әлеге шәмаилләр белән академия театры рәссамнары Сперанскийлар да кызыксына һәм ниндидер юллар белән коллекциянең бер өлеше алар кулына килеп керә. Тихон Сперанский әлеге хәзинәне өйрәнә һәм татар спектакльләре бизәлешендә күчермәләрен актив

«Татар-информ»

куллана. Аның вафатыннан соң коллекция хатыны Любовь Сперанскаяга кала. Ул исә аны соңыннан бергә яшәгән Владимир Поповка васыять итеп калдыра. Матди яктан авыр вакытта Сперанская бу коллекцияне сатарга карар кыла.

Әле дә хәтердә: бер көнне эш бүлмәсенә култык астына папка кыстырган озын сакаллы бер кеше килеп керде. Папканы ачып, эчендәге әйберләрне күрсәтә башлагач, күңелгә шик керде. Икенче бүлмәгә чыгып, Милли музейга шалтыратырга булдым. Хикмәт шунда: Попов миңа музейда саклана торган типография коллекциясен күрсәтте. Мин инде, әллә аларны музейдан алып чыктылар микән, дип пошаманга калдым. Чөнки аларны яттан беләм һәм кайберләренә тасвирлама да яздым әле. Мине коллекция урынында дип тынычландырдылар. Владимир Попов белән танышу менә шулай булды. Шуннан ул әлеге сәнгать белән кызыксынып китте һәм дәресләр алырга да йөрде. Попов – зыялы, зәвыклы, кызыксынучан кеше, русча тәрҗемәдә Коръәнне укыды, берзаман аятьләрне сайлап алып, композицияләр ясый башлады. Ә инде коллекция язмышына килгәндә, ул аны музейга тапшырырга теләде. Әмма ул чакта музейның матди яктан хәле авыр иде. Ахыр чиктә коллекция Мәскәүдәге Рөстәм Сөләйманов җитәкчелегендәге «Мәрҗани» фондына күчте. Әлеге фонд аның күргәзмәсен дә оештырды, бастырып та чыгарды.

:: Дәвамчыларым дип кемнәрне атыйсыз?

– Үзлектән өйрәндем, әмма минем бер укытучым булды, ул – Бакый Урманче. Казан дәүләт университетының филология бүлегенең дүртенче курсында укыганда, 1978 елда без, ике студент (тарихчы Искәндәр Гыйләҗев һәм мин) һәм ике мөгаллим (галимә Фәһимә Хисамова һәм фонетика белгече Хәлим Сәлимов), Бакый Урманчега каллиграфияне өйрәнергә бардык. Аның өендә тулаеп дәресләр алдык. Бакый ага безне каләм тотарга, аны ясарга, төзәтергә өйрәтте.

Татарстанда хәзер инде хаттатлар шактый. Каллиграфларның күргәзмәләре даими оештырылып тора. Монда иң элек иң көчле каллиграфларның берсе, Төркиядә белем алган Гөлназ Исмәгыйлованы атарга кирәктер. Ә инде минем шәкертләргә килгәндә, Татар дәүләт гуманитар институтында 8 ел укыттым, шактый укучылар әзерләнде, саный китсәң, күп инде алар.

:: Гарәпчә язылган кулъязмалар өйрәнеләме, бу җәһәттән архивлар ни дәрәҗәдә ачык?

– Кулъязмалар өйрәнелә һәм теләгән һәр кеше мәчетләр каршында гарәпчә укырга, язарга өйрәнә ала. Бу үзеңнең үткәнеңне белү өчен кирәк. Ә үткәнне өйрәнмичә, бүгенгене төзеп булмый, шулай бит? Бу җәһәттән институтның «Мирасханә»се ачык, аннан шактый мәгълүмат алырга була. Тик менә дәүләт архивларына керү шактый кыенлашты. Элек бу эш җайлырак иде. Шәҗәрә белән кызыксынган кеше, Дәүләт архивының Казандагы Декабристлар урамындагы бинасына килеп, кирәкле мәгълүматны ала иде. Хәзер ул Лаеш районындагы үзәк бинага күчте. Шулай да, Казанның 8 Март урамындагы бинада кирәкле документларга заказ биреп була әле. Миңа калса, бу эшне читенләштермәскә кирәк. Соңгы елларда халыкта шәҗәрә белән кызыксыну бар, бу кызыксынуны сүндермәскә иде. Тугралар белән дә кызыксыну зур. Шәхсән үзем генә дә елына пыялага йөзгә якын тугра эшлим. Тугра ул – шәхеснең билгесе. Хәзер гаилә тугралары да популярлашты. Анда ата-ана, балалары турында мәгълүмат урын ала. Аны инде хәзер туйларга бүләк итеп тә ясата башладылар.

:: Чараларда катнашканда Тукай премиясе түштамгасын тагасыз. Әлеге бүләк

турында сез нинди фикердә, дәрәҗәсе төшмәдеме?

– Тукай ул – безнең якты йолдызыбыз, маягыбыз инде. Бәс шулай икән, туры Тукай тирәсендә толерант булып кыланырга, яраргa тырышырга кирәкмидер. Шул нәрсәләр булмаса, дәрәҗәсе төшми. Мин Тукай премиясе түштамгасын бер горурлык белән тагып йөрим.

:: Сез бит – татар мәктәпләре, татар сыйныфлары булдыру өчен җан аткан кеше дә. Мәгарифтә хәлләр ничек? Артка чигенмәдекме?

– Без Казанда 16 нчы татар-инглиз гимназиясен ачуда катнашкан идек. Анда бөтен фәннәр дә татарча укытылды, гарәп теле дә укытыла иде. Аннары өр-яңа бинада татар гимназиясе оешты. Анда да фәннәр татарча укытылды. Кызганыч, гарәп теле озак укытылмады, аннары кайбер фәннәр дә урысча укытуга калды. Минем улларым татарча укып калдылар, гарәп телен дә өйрәнделәр, аннары бетте ул. Хәзер бу гимназия рус-татар мәктәбе тибында калды.

> Мин еш кына үз-үземә «Милләт булып саклану өчен нишләргә?» дигән сорау бирәм. Миңа калса, моның өчен һәр районда берне генә булса да, чиста татар мәктәбе булдырырга кирәк. Янәшәсендә рус мәктәбе дә булсын, башкасы да, әмма берәү бары тик татар мәктәбе булсын. Анда татарча укырга теләгән балалар гына белем алсын иде. Чөнки татар телен көчләп укытып кына саклап калып булмый. Без моңа инандык инде.

Телне саклау балалар бакчасыннан ук башланырга тиеш. Менә минем оныкларым саф татарча сөйләшәләр иде. Балалар бакчасында татар төркеменә бирделәр. Әмма анда татарча белмәгән балалар да шактый, нәтиҗәдә тәрбия татар телендә алып барылмый. Хәзер инде онык урысча «яра». Татар телен күрсәтергә кирәк булганда, тәрбиячеләр оныкка татарча шигырьләр бирәләр. Ул аны ятлый, кунаклар канәгать китеп бара… «Татарча сөйләүче балалар бармы?» – дип сорадым аптырагач. «Без төркемдә икәү генә», – ди…

:: Без сезнең белән бер әңгәмәдә Казанны каллиграфия белән бизәү турында да хыялланган идек. Ләкин Бауман урамындагы сезнең эскиз буенча ясалган сәгатьтән кала, башка җирдә дә гарәп язуы күренми…

– Бу – авырткан мәсьәлә. Хәтта кириллицада язылган татарча элмә такталар да бик юк бит. Элек Казан үзәгендә кунакханә маңгаендагы Татарстан атамасы күзне иркәли иде, хәзер инде ул да юк. Татар эзе җуела бара. Камал театрын алыйк. Аның йөз елдан артык тарихы бар. Шул тарихның саллы бер өлешен гарәп шрифтындагы афишалар һәм башка документлар алып тора. Әнә шул афишаларны яктылык белән эшләп, бинаны бизәп була бит. Хәзер бит бөтен җирдә яктылык белән бизәүне кулланалар. Камал театрының түбәсенә үк гарәп язуы белән яктылык ярдәмендә «Камал театры» дип язып куеп була. Бу – традицияләргә тугры калу булыр иде. Камал бит атаклы драматург кына түгел, рәссам да әле ул. Мәчетләрне дә яктылык белән бизәп булыр иде. Дөньяда андый алым киң кулланыла.

:: Иң зур теләгегез нинди?

– Татар милләте күтәрелсен иде, йөзебезне, телебезне югалтмасак иде, дип телим. Барыбызның да балалары, оныклары тартынмыйча татарча сөйләшсеннәр иде.

Әңгәмәдәш – Гөлинә ГЫЙМАДОВА

< Дәвамы. Башы 14 июль санында

АЙГӨЛ ӘХМӘТГАЛИЕВА

ТУЗГАНАК КЕРФЕГЕ

Сугыш авыл ирләрен берәм-берәм йота гына торды. Китәннәр артыннан, озак та үтми, җан өшеткеч сүзләр язылган кара хәбәрләр дә кайтырга тотынды. Мәктәп директоры булгач, Әмирханны бронь биреп калдырганнар иде. Үзалдына байтак уйланып йөргәндер, күрәсең, көзен, укулар башлангач, тотты да районга барып гариза язды.

Иренең үзе теләп ут эченә җыенганын ишеткәч, Хәдичә ни диярге дә белмәде. Әмирханның холкын белә – тешләгән җирдән өзә торган заттан. Моңа кадәр дә ир хакын хаклап яшәгән хатын сабыр гына:

– Үзең беләсеңдер, – диюдән узмады.

– Болай булмый, эшли алмыйм мин, Хәдичә. Мәктәпкә барсам, аталары үлгән балаларның, урамга чыксам, ире үлгән хатыннарның күзенә карый алмыйм. Мондый утта янганчы, сугыш эчендә бүтәннәр белән кайнавың мең артык, – диде Әмирхан терсәгенә таянып өстәл артында утырган җирдән.

Унынчы яше белән барган Сәет әтисенең фронтка китәсен ишеткәч, сөенеп туймады. Алайса, малайларның: «Сиңа рәхәт», – дип төрттерүләре үзәгенә үтә башлаган иде. Кулына кылыч йә мылтык тотып, сугыш кырында дошманны кырып йөргән әтисен күз алдына китерү үзе үк бер горурлык өстәп җибәрде.

– Әткәй, син миңа сугыштан чын курчак апкайтырсың әле. – Алты яшьлек Гөлсәйдәнең үз кайгысы кайгы иде. Ул ике нәзек толымын мәзәк селкетеп, әтисенең култык астына кереп утырды. – Ике аягы да, ике кулы да булсын. Күлмәге дә булсын.

– Ярар, кызым, апкайтырмын. Исәнимин булырга гына язсын. – Әмирханның бер-берсенә кушылып торган кашлары язылып китте, кояшта янып каралган озынча йөзенә дә, кысынкырак кара күзләренә дә ниндидер яктылык сибелде. Улының Гөлсәйдәгә кызыгып карап торганын абайлап, Сәетнең иңбашыннан кочып алды, күкрәгенә сыендырды. Хәдичә, кулы бер эшкә дә бармыйча, аптыраган кыяфәттә мичкә сөялеп тора иде, кинәт кенә күңеле тулды. Күз яшьләрен күрсәтмәскә теләп, тиз генә мич аралыгына кереп китте.

– Юкны бушка аударып утырганчы, мин барында бәрәңгене алыйк без, әнисе. Үзегезгә генә авырга туры килер. – Әмирхан, шулай бит, дигәндәй, Сәеткә карап күз кысты.

– Бәрәңгесе качмас. Үзеңне карарга кирәк. – Алъяпкыч итәге белән дымлы күзләрен сөртергә өлгергән Хәдичә, нәрсәгә барып тотынырга белмичә, ыгы-зыгы килде. Казанга су салды, астына салам ягып җибәрде, нәрсәләр генә хәстәрлим икән дип, утка-суга төште.

Әмирханның исә сүзе сүз иде: ир-ат кулы барында бәрәңге алыйк, дип өзмикуймый бакчага чыгарга күндерде.

«Су кайнап чыккач эндәшерсең», – дип, казан астын карауны Гөлсәйдәгә калдырдылар да өчәүләп бакчага чыгып киттеләр.

Салам янганны күзәтеп утыру кызга башта гына кызык тоелды. Урындык өстенә менеп, Гөлсәйдә түгәрәк капкачны әллә ничә тапкыр ачып карады – казандагы суның тиз генә кайнарга исәбе юк иде. Өелеп торган салам өстендә сикергәләп уйнады – ул шөгыль дә тиз ялкытты. Өйләре бәләкәй шул, әллә нинди маҗаралар уйлап чыгара алмыйсың. Дүртпочмаклы өйнең яртысын диярлек шушы мич алып тора. Өстәл янындагы сәке дә байтак урынны били. Ишегалдына караган ике тәрәзә арасына китап тезелгән агач шүрлек эленгән иде, дәфтәр-китаплары күбәйгәч, әтисе ул шүрлеккә агач аяклар өстәп куйды да анысы зур бер шкафка әверелде. Стенага терәп куелган тимер башлы караватны да исәпкә алсаң, идәндә басып йөрергә урын да юк шикелле.

Мич алдына сузылган бауга кибәргә дип мендәр тышлары эленгән иде, тискәре ягына әйләндерелгәнгә, тегеннәнмоннан мәзәк булып җепләре асылынып тора. Кыз казан астына тагын салам ташлады да көйри башлаган бер салам бөртеген кулына алып, шул җепләргә ут элдерергә тотынды. Буй-буй сузылып төшкән җепләрнең башта берсе кызарып-каралып янгандай итте дә пыскып сүнде. Кызык шөгыль уйлап табуына куанып, Гөлсәйдә икенче җепкә дә ут көйрәтте, өченчесенә… Аларны күзәтү шундый кызык иде, үзалдына кеткелдәп мавыккан кыз мендәр тышының яна башлавын искәрми дә калды. Күргәч, чырыйлап кычкырды да ишекне ачып, тышка ташланды. Бәхетенә, нәкъ шул минутта Сәет абыйсы, чиләк белән бәрәңге күтәреп, бакча капкасыннан чыгып килә иде. Гөлсәйдәнең:

– Абы-кай! Әнкәйнең чигүле мендәр тышы яна-а-а! – дип сузып чырылдавын ишеткәч, чиләкне җиргә ташлады да өй эченә йөгереп керде. Ут мич алдында яткан саламга да төшкән – анысын таптыйтаптый сүндергәч, Сәет кисмәктәге суны чүмечләп сибәргә тотынды. Ярый әле зурга китмәде, мендәр тышлары харап булды да идән тактасы кара көеп чыкты.

Әтисе белән әнисе пыр туздырып әрләр дип, Гөлсәйдә шүрләбрәк калган иде, ни хикмәттер, алар беркадәр акыл өйрәтеп битәрләп алдылар да:

– Нигә алай иттең инде, кызым? – дип сорап кую белән генә чикләнделәр.

Батыраеп киткән Гөлсәйдә:

– Бәй, ул җепләр үзләре асылынып торгач ни… – дип, бик ансат котылды.

– Балалар, мин киткәч, әниегезгә терәк булып сез каласыз. Сәет улым, таякның авыр башы синең иңсәгә төшәр, син – ир-егет. Уенны онытып торырга туры килер. – Әмирхан, чүпрәк сумкага юл әйберләрен тутыра-тутыра, Сәетнең чандыр гәүдәсенә кызганулы караш ташлады. Аннан урындыкта аякларын селкеп утырган Гөлсәйдәгә борылып: – Кызым, бүтән берүк ут белән уйный күрмә, ишетсен колагың! Мин кайтканчы яхшылап укырга-язарга өйрәнеп куй, яме! – диде, үрелеп аркасыннан сөйгәч. – Ничек кенә авыр булса да, балалар укысыннар инде, Хәдичә, белемсез беркая да баралмаслар… – Монысы – кипкән икмәк кисәкләрен сөлгегә төреп маташучы хатынына төбәлгән сүзләр булды.

Гөлсәйдә өчен өр-яңа тормыш башланды. Аны сабыйлык иленнән бик иртә аерып, балачагын, әтисен урлаган тормыш иде ул. Гөлсәйдә дә, Сәет тә, ул чорның меңләгән, миллионлаган балалары кебек, кинәт олыгайдылар.

Ир-егетләрсез калган авыл үзе дә күз алдында картаеп китте.

Ике бала белән ничекләр дөнья көтәрмен дип хәсрәткә төшкән иде Хәдичә, алтышар-җидешәр бала белән торып калган хатыннарны уйлагач, бераз тынычланды. Ил белән килгәнне ничек тә күтәрерләр әле. Үзәгенә үткәне – ирен сагынып тилмерү йә булмаса балаларына ни ашатырмын дип борчылу түгел иде. Әмирхан киткәннән соң батыраеп калганнар аның кулак кызы икәнен бик тиз исләренә төшерделәр. Үлгән арысланга куян да тибеп китә, диләр бит, кайберәүләргә, үз хәсрәтләрен читкә куеп, тел чарларга менә дигән сәбәп табылды. Гүя башка хатыннар белән көнне төнгә ялгап колхоз эшендә йөргән Хәдичәнең генә маңгаена мөһер сугылган. Бригадир булып эшләгән Мирхәттән аеруча тынгы юк: чөгендер йолкыганда ике сүзнең берендә: «Кулак кызларының кулы моның ише әйбер тотып үсмәгәндер», – дип теш ыржайтып, бөтен басуны яңгыратып торды. Кай җире килешмәгәндер – аны сугышка яраксыз дип тапканнар икән. Карап торышка аяк-кулы – барысы да үз урынында югыйсә.

– «Бер күз гүпчим күрми, икенчесе дә әлле-мәлле генә», – дип сөйли инде үзе, этем белсен, – дип аңлатты Хәдичәнең ахирәте Нәсимә, шул хакта сүз кузгаткан бер кичне.

Әмирханга кияүгә чыгып, Усайга килен булып төшкәннән бирле Хәдичәнең артык җәелеп аралашкан кешеләре булмады, чапырыш күршесе, үзенең яшьтәше Нәсимә белән исә серләре килеште. Нәсимә бианайлы йортта яши, Хәдичәне сер сыяр, эч бушатыр ахирәт күреп, бик тиз якын иткән иде. Аның Каюмы сугышның өченче көнендә үк китеп барды, шуннан бирле өенә ике хат килгән килеш, соңгы араларда бер хәбәре дә ишетелми. Нәсимәнең төпчек кызы Асия Гөлсәйдә белән бер яшьтә, тәпи киткәннән бирле агылый-тагылый булып гел бергә йөриләр. Олы кызы Рәфисәгә карап кына һәммәсенең йөрәге яна: берничә ел элек, Нәсимәгә ияреп амбарга менгәч, кызның аягы силос турау машинасына эләгеп гарипләнде.

– Күзләр генә тиде кызыкаема, – дип, торган саен өзгәләнә Нәсимә. – Алдынартын күрми чаба торган ие бит. Йөгерешче булыр бу, дип, сөйләнә торгач, күз генә тигерделәр! И-и, Хәдичәкәем, шул чакларда ничекләр аңымны җуеп егылмаганмын да ничекләр итеп сабыйкаемны Пучы бүлнисенә алып барып җиткерә алганмын диген. Чәрдәкләнгән аяк сөякләрен соңыннан алъяпкычыма җыйдым бит, күз яшьләремә чыланып бетеп, тезләнә-тезләнә сөяк җыйдым! И-и, бала хәсрәткәйләре… Аның сызлануларын үземә генә алыр идем дә, юк шул, алыплар гына булмый… Ярар инде, гомеркәе булсын берүк…

Кырык икенче елның Яңа елын Нәсимә тол хатын булып каршылады – шул көнне аңа Каюмның үлү хәбәрен китереп тоттырдылар. Ике кызын кочаклап, әй үкседе утыз яшьлек Нәсимә, идәннәрне тырнап елады, кайгыларын җиңеләйтер чаралар гына юк иде.

Кышка кергәннән бирле Гөлсәйдәнең эше катыланды, кыз тырыша-тырыша язарга өйрәнә иде. Ник дисәң, әтисенең хаты килгәч, әнисе дә, Сәет тә аңа аерымаерым җавап язалар, ә Гөлсәйдәгә, яза белмәгәч, кулын төшереп җибәрергә генә кала. Абыйсы әле анысына да сукрана, янәсе, болай да кәгазь юк, каты басмый гына хат өстенә төшер, ди. Аннан, әтисе һәр хаты саен әнисенә: «Балаларны какма, ничек тә укытырга тырыш, Гөлсәйдәне көзгә берүк мәктәпкә бир», – дип, кат-кат әйтеп тора. Хәрефләрне өйрәнсә, кыз берсенә дә ялынып тормас иде әле, күңелендә булган бар нәрсәне әтисенә бәйнә-бәйнә үзе язып салыр иде. Әнә кәҗә бәтиләрен быел да мич аралыгына кертеп яптылар. Һәрберсенең ике аягын кешәннәп* куйгач, и җәлләде үзләрен Гөлсәйдә. Мескеннәр, рәхәтләнеп чабыша да алмыйлар.

**кешәннәп – диал., тышаулап.*

Дәвамы бар >

Бу кешеләрне Сабантуйда очратырга була

Уены-чыны бергә

✓ Аксыл классик чалбар белән шундый ук сеткалы ак ботинка кигән абзаңны. Аның оекбашы, әлбәттә, кояштан саклаучы күзлеге кебек үк кара.
✓ Алгы ягы сеткалы футболка һәм башына панама кигән егетне.
✓ Баш түбәсенә генә «Әллә нәрсә агро 2016» дип язылган бейсболка элгән нәчәлникне.
✓ Түбәтәен батырып кигән шактый гына капкан абзыкайны (Сабантуй тәмамлангач, мәйдан кырыенда ятып калучы да шул).
✓ Биек үкчәле туфли киеп, чирәм арасында ник туганына үкенеп йөрүчене.
✓ Артистлар җырлаганда мәйданга чыгып берүзе биючене.
✓ «Быел көрәш матур булмады», – дип зарланып йөрүчене.
✓ Син Сабантуй карарга төшеп кенә барганда, инде арып-талып өенә кайтып килүчене.

Айваз САДЫЙРОВ

Әз-мәз мәзәк

Имеш, Менделеевның төшенә башта кефир электролизы, коллайдер инструкциясе, «Рекорд» телевизоры микросхемасы кергән булган. Әмма ул берни аңламаган.

* * *

– Доктор, минем сезнең янга әле озак йөрисем буламы?
– Ипотекам беткәнче.

* * *

Доклад. Бүгенге эш нәтиҗәләре түбәндәгене күрсәтте:
1) Гарык булдым!



Сканворд җаваплары

Горизонталь: аяк, Кирам, бер, укыту, кылыч, Испания, Ра, яман, Антарктида, Әрәпә, Мао, ал, тукран, ши, Стенли, Адәм, ияк, ир, урам, фараз, Мәдинә, Арампо, Сяо, тары, әзи, Нәнәгәр, каратай, ару, Си, Ржев, Алиса, дан, Эльвира.

Вертикаль: Сарман, сарут, Егудин, алпан, лаун, Акчурин, Рәшә, сакэ, фа, Раил, артык, Амур, мат, Иль, тырнак, ракурс, амбулатория, ара, Жади, Камыр, ар, Карачурина, арвана, дефолт, ятьмә, Ми, Мирсәй, адаш, Раяз, Налим, Зоил.

Сәхифәне Данил СӘФӘРОВ әзерләде

Беләсең килсә...

1 Фидель Кастро, илбашы кәнәфиенә утыргач, нинди уенны тыйган?
а) бильярд;
б) покер;
в) монополия.

2 Гамофобия нәрсә ул?
а) ялгыз калудан курку;
б) туйга бәйле һәр нәрсәдән курку;
в) үз җенесеңдәге кешеләрдән курку.

3 Минзәлә театры кем исемен йөртә?
а) Туфан Миңнуллин;
б) Сабир Өметбаев;
в) Аяз Гыйләҗев.

4 Бу шәһәрдә Россия валютасы – сумга һәйкәл юк:
а) Пенза;
б) Сыктывкар;
в) Томск.

Җаваплар: 1. в); 2. б); 3. б); 4. а).

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Индекс П2435
Тираж – 14042 данә

Газетага сертификат бирелде
Заказ 303

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+